## Ирек сабиров
## Ләззәт тышкыны
## Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты

**2010**

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

**С12**

**Сабиров, И.Н.**

Ләззәт ташкыны : шигырьләр / Ирек Сабиров. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 112 б.
ISBN 978-5-298-01928-6
Шагыйрьнең әлеге китабына соңгы елларда иҗат ителгән лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

УДК 821.512.145-1

**ББК 84(2РОС=ТАТ)-5**

**ISBN 978-5-298-01928-6**

© Татарстан китап нәшрияты, 2010

**© САБИРОВ И.Н., 2010**

Шигърият һәм гакыл исән чакта,

Корып егылганчы соңгы гөл,

Бүгенгене камил итү кирәк,

**БҮГЕНГЕНЕ... ӘЛЕ СОҢ ТҮГЕЛ!**

**ВАКЫТ**

Яшьли эш күп, вакыт тыгыз иде,
Күп булса да утын учакта;
Олыгайгач, көннәр бушар, диеп
И юана идек яшь чакта.

Олыгайдык. Тормыш китабының
Калынлыгы икән – Һәфтияк.
Тагын да аз вакыт очып үтә,
Сәгатьләрне юкка харап итә
Әллә нинди фани вак-төяк.

Өлгермибез. Кояш – баешларда.
Туганнар да үрчи, танышлар да
Күбәйгәннән бара күбәеп;
Куллар җитми язу-сызуларга,
Кулъязмалар ята күгәреп.

Үкенермен... Чәнчелеп лә китсен
Вазифасы, малы, дачасы!
Бер чумарга иде җырларыма...
...Әллә далаларга качасы?

**ВАГОН ТӘРӘЗӘСЕННӘН**

Хәйран калып барам: нинди генә
Байгыш җирләр юк бу дөньяда!
Кара, малай, адәм балалары
Яшәп ята икән монда да!

Әле алар безгә охшаган бит,
Булсалар да бездән бик ерак:
Йөзләре дә безнекедәй моңсу,
Шул ук сагыш, шул ук былчырак...

**МИН**

Юлларымның төрле елларында
Төрле төстә булдым мин үзем.
Андый идем, мондый булдым димим,
Гөнаһлардан тәүбә кылдым димим,
Холкым үзгәрешле, диюем.
Булды мактап күккә чөюләр дә,
Ләгънәт төшсен сиңа, диюләр дә.
Мин гел үзгәлекләр эзләдем,
Яраттым шул таныш-дусларымның:
«Бу бит безне көтмәгәндә тагын
Шаккатырды», – дигән сүзләрен.
Калыр җирдә шаккатыру даным,
Бүтән юньле даным калмаса...
...Хак Тәгалә биргән бу тормышта
Гөнаһы да ямьле ләбаса!

**ИҖАТ**

Нинди генә язмышлар юк җирдә!
Түрдән гүргә юллар – туп-туры.
Булдыралсам, роман язар идем,
Булдыралмыйм, каһәр суккыры!

Каян булсын роман ише күләм!
Төн утырып, шатлыгымнан үләм,
Тагын бер дүртьюллык шытты, дип...
Ярар инде. Әле шигыре дә
Хәйран гына булып чыкты бит.

**ТАРИХ**

Каян синдә, гасыр, бу афәт ташы?
Хәвеф арта: үз-үзен дөнья ашый...

*Рәдиф Гаташ*

Каннар коеп, адәм балалары
Бәхет яулый. Инде янгыннары

Мең гасырлар буе сүрелми.
Җиңелгәннәр байтак. Җиңгәннәр күп.
Әмма бәхетлеләр күренми.

**КӘККҮК**

Кәккүк моңы ишетелгән чакта
Ышанасың, ахры, син чынлап та,
Еллар санап: «Тагын чак кына!..»
...Ул бит аваз сала аянычтан:
Чит ояда үсеп таралышкан
Балаларын елап чакыра.

**БӘЛӘБӘЙ**

Җепшек бер көнендә елның
Килеп чыктым Бәләбәйгә;
Барып төшкән кебек булдым
Карлы кыштан гөлле җәйгә.
Һәр җан монда – бер асылташ,
Зиннәт туе – шигъри бәйге;
Шуңа мин дә сезнең якташ,
Мин дә хәзер бәләбәйле.
Ирләр аек, кызлар чибәр,
Йөзләр көләч Бәләбәйдә;
Һәр кунакка җылы сүз бар,
Һәр йорт әйди сыйга-чәйгә.
Шытып килә яшел чирәм,
Җир уяна бакчаларда...
Чакырсалар, тагын киләм.
Хәер, чакырмасалар да...

**ХЫЯНӘТ**

Безгә түгел, бүтәннәргә генә
Килү мөмкин кебек кыямәт:
Кайнап торган шушы мәхәббәткә
Ничек итеп керсен хыянәт?

Күзләреңне миңа төбисең дә,
Тик синеке генә мин, дисең;
Ятлар назын белмәгән дә кебек,
Кочагымда изрәп эрисең.

...Әмма иләсләнгән мизгелемдә
Эчеп чәчләреңнең хуш исен,
Мине үпкән кайнар сулышыңнан
Ишеткәндәй булдым ят исем...

**ЯШИК...**

Ә каләмем миңа, синең гомер
Мәңгелек, дип гүя пышылдый...

*Рафис Корбан*

Кеше җаны, диләр, мәңге яши,
Галәмнәрдә эзләп изгелек;
Фани дөнья хәсрәтләре, имеш, –
Мәңгелекнең бары мизгеле.

Ләкин нигә икән минем җаным
Галәм киңлекләрен сагынмый?
Авыр чакта: «Китәм моннан», – дими,
«Яшим әле җирдә тагын», – ди.

Канәгатьлек белән китәр өчен
Өлгердемме җирдә, нишләдем?
Юк, юк, җаным, бик күп калды әле
Бурычларым монда, эшләрем.

Язмышым бит тормыш юнәлешен
Әле генә табып, юл сала...
Газиз җаным! Яшик әле җирдә
Тагын өч-дүрт гасыр булса да...

**АКЫЛ**

Акыл сату җиңел. Әмма никтер
Сатып алып булмый акылны...

*Зөлфәт*

Хәзер генә аңладык шул, пәйда
Булгач кына чигә чаллары:
Безгә акыл сатып йөргәннәрнең
Акыллары булган чамалы.

Без аларны олуг диеп белдек,
Ә чынында икән – куыклар;
Чын акылны эчкерсезлек белән
Бирде безгә бүтән олуглар.

Тәкәбберләр, хирыслылар узды,
Ә олуглар – һаман янәшә.
Акыллылар сатмый акылларын,
Алар аны бушлай өләшә.

**НИШЛӘМӘК КИРӘК?..**

Язга ышандым, талпынып алдым,
Кабынган теләк тапмады терәк.
Әй тиле йөрәк, дуамал йөрәк,
Сиңа ни кирәк, сиңа ни кирәк?
Язга шатландым, кабат алдандым,
Үземне сиңа тиң диеп уйлап.
Могҗиза диеп юкка ышандым:
Адәм юлында булмый инкыйлаб.
Язга алдандым, юкка шатландым:
Талпынды гына таушалган йөрәк.
Вакытлар үткән, гомерләр беткән.
Нишләмәк кирәк?.. Нишләмәк кирәк?..

**ЕЛЛАР ҮТКӘН**

Туган кырлар... Сөләнгернең шадра
Көзгесендә таллар чагыла.
Өр-яңадан бер әйләнеп кайткан
Кебек булдым малай чагыма.
Ләкин еллар үткән, гомер беткән,
Йөрәк кенә әрнеп тыпырдый.
Туган өйнең иске капкасы да
Ят көйләрне көйләп шыгырдый.

**МӘГЪНӘ**

«Нидә максат? Ник?» – дип сораштырып
Байтак гиздем дөнья сәхнәсен;
Таушалып та, картаеп та беттем,
Эзли-эзли тормыш мәгънәсен.
Хәзер инде еллар үткән саен
Ныграк баса шөбһә күңелне:
Мәгънә эзләп, җирдә рәхәтләнеп
Яши алмый калам түгелме?

**ҮКЕНМИМ**

Үкенмим мин. Үткән-беткән инде
Адашулар, бурыч-вәгъдәләр;
Ялгыштым, дип, кире кайтыйм, диеп
Зар елаудан нинди мәгънә бар?

Әйдә, димен, үкенешеп түгел,
Яшик киләчәккә юл ачып!
Дәртле рухта шулай көннәр буе
Йөрим дусларымны юатып.

Ә кичләрен хатирәләр баса:
Алар моңсу, алар сизгерләр...
Үкенмим, дип шапырынсам да шул,
Үкендерә кайбер мизгелләр...

**ТАТАР БӘЙРӘМЕ**

Җәйнең матур көнендә
Илнең бөтен җирендә
Җыелышып татарлар
Сабан туе ясарлар...

*Гәрәй Рәхим*

Сабан туе гөрли, сабан туе!
«Алмагач»ын җырла сызгырып!
«Хезмәт туе», – диеп, гармуныңда
Сәйдәш көен җибәр сыздырып!

Җилләре дә бүген әллә нинди
Тантаналы, горур, серлеләр.
Шул җилләрдә уйнап җилфердиләр
Милли бизәк чиккән сөлгеләр.

Түрдә торсын тәмле бал-чәйләре,

Чәчәк бәйләмнәре, җәй яме;
Шаккатырып Рәсәй халыкларын,
Шау-гөр килә татар бәйрәме!

**ЭКСПРОМТ**

Бәгырькәем, уфтанма син
Сентябрьгә;
Без җиңәрбез көзен, кышын
Икәү бергә.
Бар эшләрем, җимешләрем –
Синең өчен;
Син булганда, икеләтә
Арта көчем.

**ТАТАРЛЫГЫМ**

...Татар халкы һаман исән, чөнки аның тамырлары нык. Татар кешесе, кайда гына яшәмәсен, үзенең татарлыгын онытмый.

*Индус Таһиров*

Еллар узган саен, күбрәк
Сизәм җирдә ямь барлыгын:
Язмыш каккан-суккан саен
Ныгый бара татарлыгым.

Булды үзе аптыраган
Мәлләрем юл чатларында;
Ят тарафка, бүтән юлга
Кереп киткән чакларым да.

Хәлсез ауган җирдән мине
Ни күтәрде, ни коткарды?
Чытырманнан туры юлга
Нинди куәт алып барды?

Ул – серле көч. Маңкортларга
Һич аңлатып булмый аны:
Ул көч – мине кеше иткән
Татар каны, татар аңы,

Ходай биргән яшәү дәрте,
Тән һәм әхлак чисталыгы,
Борынгыны бүгенгегә
Тоташтырган җеп барлыгы.

Шуңа күрә җиңеп барам
Рух чирен һәм уй тарлыгын;
Айлар-еллар узган саен,
Ныгый бара татарлыгым.

**ИКЕ ВАТАН**

Туган як – бер. Аңа алмаш булмый.
Истә көннәрен дә, төнен дә.
Дөньяның иң яшел үләннәре
Үсә безнең капка төбендә.

Туган яктан еракларда узды
Гомеремнең байтак көннәре.
Бу – икенче ватан. Монда гына
Дөньяның иң зәңгәр күлләре.

Ике ватан. Мин аларны үзем,
Үз теләгем белән сайламадым, –
Өлешемә шулай тигәндер:
Берсен Ходай биргән. Икенчесен...
Анысын да Тәңрем биргәндер.

**СОҢ БУЛЫР**

Ашыгып, эш диеп, мал җыеп,
Көннәр дә, еллар да үтәләр.
Ә безне яраткан сылулар
Көтәләр, көтәләр, көтәләр.

Без эшчән, без дөнья куабыз,
Күрмичә иң гүзәл таңнарны;
Без мәхрүм итәбез назлардан
Иң тугры, фидакарь җаннарны.

Югалту бик җиңел аларны,
Булса да мәңгелек кебекләр.
Әй, бүген назлыйк ла ярларны,
Иртәгә соң булыр, егетләр!

**ҖАВАП**

Тәнкыйтьлисең мине: «Әллә, – дисең, –
Утыныңмы беткән учакта?
Бүтән кеше әйткән фикерләрне
Кабатлыйсың, – дисең, – кайчакта».

Юк, дускаем, мин бит, кешелеккә
Хак сүзләрдән керсен, дип, сихәт,
Югалмасын, диеп, тирән акыл,
Мәңге яшәсен, дип, хакыйкать,

Кыргый ташны кырлап шомартам да
Әйләндерәм йөзек кашына,
Кичә акбур белән язылганны
Бүген уям кыя ташына.

**КУЛЪЯЗМАЛАР**

Без кемнәр соң? – Ходайдан ваз кичкәннәр?
Күңеленнән иман нуры киткәннәр?

*Рәдиф Гаташ*

Өем-өем иске кулъязмалар...
(Язган чакта – ләззәт, куаныч.)
Күп язылган. Кая куйыйм аны?
Ертып ташлар идем – кызганыч.

Кулларыма каләм алган саен
Шөбһәләнәм тагын, тагын да:
Укый торган, аңлый торган җаннар

Калды микән тирә-ягымда?

**БЕРӘҮ ГЕНӘ ГОМЕР**

Гөл-чәчәкле, нурлы бу дөньядан
Шуып үтте бары күләгәм.

*Рәфикъ Юныс*

Кабатланмас инде
Алсу таңнар,
Кабат тумас мине
Яратканнар.
Яшәү кадерләрен
Белмәдем шул;
Кайчан өзелер бу
Бормалы юл?

Сарыкүлдә томан
Җете зәңгәр;
Кичерегез, зинһар,
Рәнҗегәннәр!

Кими бара куәт
Йөрәгемдә.
Берәү генә гомер,
Берәү генә...

**ХАТИРӘЛӘР**

Дәфтәр битен ачсам, ул Истәлек
Килеп чыга кипкән гөл булып.

*Рәмис Аймәт*

Хатирәләр, бәйләвечләр кебек,
Яраларда кипкән ябышып.
Куптарма син аны, ярсымасын.
Вакыт узган. Булмас кавышып.

Сагынсак та тәүге мәхәббәтне,
Кайтмас, бәгърем, кире ул чаклар.
Еллар аша инде күренми дә
Су буенда янган учаклар.

Без яраткан гөлләр түтәлләрдә
Утыз биш кат шытып, сулдылар;
Бергә үскәннәрнең байтаклары
Каен кәүсәләре булдылар.

Ерактагы йолдыз яктысыдай
Калсын тойгыларның яшь чагы.
Сөю кояшының баешында
Кызыллана хәсрәт шәфәгы.

**ЧАБЫШ**

Шимбәләрнең, пәнҗешәмбеләрнең
Үкчәләре генә ялтырый!
Әлсерәтте бу чабышлы тормыш.
Тәнем арды. Йөрәк ял сорый.

Җитте, дидем, тукталырга кирәк,
Куанырга кирәк һәр таңга!
Чаңгы киеп, дөнья мәшәкатен
Ташлап чыгып киттем урманга.

Менә икән кайда яшәү яме!
Уйлар бүтән монда, уй башка!
Карга чумган нарат егетләре
Яңакларын куйган кояшка.

Алсу көртләр, күкнең зәңгәрлеге
Сулган хисләремне исәртә,
Каеннарның шәрә гүзәллеге
Усалланып каткан күңелемне
Әллә ничек итеп нечкәртә.

Айныгандай булдым: дөнья куып,
Күпме мизгелләрем урланган!
Ләззәтләнеп шулай, үзгәрдем дип,
Яңардым дип кайттым урманнан.

...Иртәгесен исә өермәдәй
Кабат йотты тормыш агышы:
Дүшәмбеләр, җомга, якшәмбеләр...
Дәвам итә дөнья чабышы.

**БӘНДӘ**

Минем күршем Битаманда
Үскән туып,
Балалары җитеп килә
Урыс булып.

«Ну и што, – ди, – по-татарски
Белмим я сам».
«Ник оныттың үз телеңне?» –
Дип сорасам,

Тәкәбберлек белән йөзен
Чөерә дә:
«Ул языкның пользасы юк», –
Дип җибәрә.

Ә мин уйлыйм: йә ул юләр,
Йә мин ахмак.
Әле дә яшим Тукай шигырь-
ләрен ятлап,

Әле дә «Зәңгәр шәл»не укып
Яшем түгәм,
Телем аша яшәвемнең
Ямен күрәм.

Үз телемдә беләм Җирнең
Һәр кыйтгасын,

Матдәләрен һәм тапкырлау
Таблицасын.

Татар мәктәбендә укып
Алдым белем,
Урыслардан шәбрәк беләм
Урыс телен.
«Ә син, – димен, – гомер кичтең
Надан килеш:
Русчаң зәгыйфь, татарчаң да
Әвеш-түеш.

Кайда кыйблаң фани дөнья
Агышында?
Җилкәнең дә, тоткаң да юк
Тормышыңда».

Шулай дидем, ә үземнең
Йөрәгемдә
Нәфрәт тә юк, ачу да юк,
Җирәнү дә.

Тик кабатлыйм, шул күршемне
Күргән саен:
«Ач күзләрен ул бәндәңнең,
Йа Ходаем!»

## **МӘСКӘҮ. КЫЗЫЛ МӘЙДАН**

Мәскәү манараларына
Карап уйланам кайчак:
Анда безнең мәчетләргә
Охшаганнары байтак.

Бусы Әҗем мәчетедәй,
Кара әле менә син:
Хәзер азан әйтә башлар
Кебек шуннан мөәзин.

Әйтерсең лә килеп чыктым
Нариман почмагына;
Тик ай түгел, якут йолдыз
Куелган очларына.

Нәкышләрнең кайберennән
Таныш моңнар сибелә:
Итальяннар арасында
Татар кулы сизелә.

Әллә Мәскәү риваяте
Тарихи бер ялганмы?
Соларилар арасында
Сабирлар да булганмы?

Һәркем бу хәлдән, минемчә,
Мондый нәтиҗә ясар:
Аллага шөкер, туганнар,
Кайда гына юк татар!

## ИКЕ ТОРМЫШ

Минем кебек кем бар икән җирдә
Ике эзгә бүлгән бер юлын?
...Хакимият дигән тимербетон
Һәм шигърият дигән киң болын.
Хакимият дигән өметсезлек
Һәм шигърият дигән ышаныч:
Булмаганны булдырмакчы булып
Ут һәм бозны бергә кушам ич!
Ике тормыш белән яшәмәкче
Булган тагын кем бар бу җирдә?
Хисе корып кипкән түрә дә мин,
Бер дуамал чая шагыйрь дә...

## АКЧАРЛАК

*Шәүкәт абый Гайнуллин истәлегенә*

Дулкыннарда йөзгән бер акчарлак
Көтмәгәндә өскә юл алды,
Күкләр киңлегендә ак болытлар
Арасында эреп югалды.

Гаҗәп: элек сизмәгәнмен икән
Яр буенда аның барлыгын.
Хәзер исә сискәндерә бушлык,
Ятимлектән әрнеп зар елыйм.

Ничек күрим ансыз җәй таңнарын,
Ничек кичерим дим кыш аен?
...Кайлардадыр күкләр зәңгәрлеген
Гизеп оча газиз кошкаем.

## БЕЗ

**1**

Кайчак хәсрәт баса йә эч поша,
Кайчак мавыгыбрак китәбез...
Әй, беләсе иде, бу җиһанда
Тәңребезгә кирәк микән без?

**2**

Иман белән генә мөмкин яшәү,
Шулай гына җанлы-тәнле без.
Тәңребезгә кирәкме без, белмим,
Әмма безгә кирәк Тәңребез.

## БҮГЕН ШАТ МИН

Фәкать хәсрәт туфрагыннан гына
Шытып чыга олуг шигърият.
Чөнки тормыш – үзе бер фаҗига,
Чынга ашкан һичбер зур ният
Бәхет белән тәмамланмый җирдә.
Ә шигырь бит тормыш юлдашы.
Шуңа, ахры, шатлык көннәремдә

Һич ярала алмый моң башы.
Язармындыр соңра газәлемне,
Яшем түгеп һәрбер сүзенә.
Бүген шат мин. Куям каләмемне.
Чиш төймәңне. Кара күземә.

**КАЙТЫРБЫЗ**

Безне ерак, ерак ыргытканнар...
Кайта-кайта хәлләр калмады.

*Харрас Әюп*

Туган яктан ерак китсәк тә, без
Югалмадык әле дөньяда:
Тегендә дә сынатмаган идек,
Кеше булып калдык монда да.

Матур монда айлы кичләре дә,
Таңнары да балкып яктыра,
Тик барыбер Убса урманнары
Төнлә төшкә кереп чакыра.

Без бит Казан арты егетләре,
Күк ишелеп, җирләр упса да,
Бер кайтырбыз әле Мәмдәлләргә,
Бер кайтырбыз әле Убсага!

**ГАРМОНИЯ**

Безнең фани дөньябызга илаһи бер моң ия,
Бу гаҗәеп могҗизаның исеме – гармония.

Ансыз булмас иде җирдә мәхәббәт тә, нәфрәт тә,
Игезләрдәй булыр иде ләззәт белән михнәт тә.

Йә кычкырып елар идек, язмыш мәзәк күрсәтсә,
Йә шаркылдап көләр идек, төшкән чакта хәсрәткә.

Бу серле моң тәэмин итә гаиләдә бereклек,
Шуңа күрә Җир йөзендә дәвам итә тереклек.

Әнкәм назы, әткәм сүзе, сөйгәнемнең күзе ул;
Ахры инде гармония – Хак Тәгалә үзе ул.

Парлап, сайрап гомер итсен Җирнең бар җан иясе,
Яшәсен лә бу Җиһанның бөек гармониясе!

**ТАГЫН...**

Чәнчер энәләрең барын
Оныттым – кагылдым шул;
Табындым да яшьлегеңә,
Үзем дә кабындым шул...

*Рәдиф Гаташ*

Тагын язлар.
Тагын сыкрый күңел.
Һич аңларлык түгел бу хикмәт:
шагыйрьләргә
куандырып түгел,
сызландырып килә мәхәббәт.

Әйтерсең лә алда әле кышның
иң дуамал явыз бураны...
Әллә йөрәк
килгән һәр шатлыкның
китәчәген белеп торамы?

**ALMA MATER**

Тәннәр яшәп тузды.
Кайттык, килсә дә көз:
Шушы йортта узды
Яшьлек көннәребез.

Монда кайнап торды
Иҗат, сәнгать, фәннәр;
Балкып, ямьнәр бирде
Шәмдәлләрдә шәмнәр.

Ул чак без заманга
Булдык бик мөкиббән...
Әйдә керик, монда
Шул ук яшьлек микән?

Монда ямьнәр бирә
Шул ук шәмнәр микән?
...Ә, юк, шәмдәл генә...
Шәмнәр янып беткән...

**«АЛТЫН ГАСЫР»**

Гыйбрәтләрдән тарих гыйбарәттер...
*Лена Шагыйрьҗан*

«Алтын гасырыгыз булган» диеп
Һәр милләтне алдый чал тарих.
Шуңа кайчак дулап китә халык:
Данлы чорны, имеш, кайтарыйк.

Ләкин... «алтын гасыр» – уйдырма ул,
Шомсыз ирек юк бу дөньяда:
Йә бөлгенлек, йә сәяси давыл
Һәм ялвару карап кыйблага.

Гомер бирәү генә! – ул да юньсез.
Бәхет эзләп кая барасы?
Шуңа матур әкиятләр эзләп
Яши мескен адәм баласы.

Менә шулай үзебезне алдап
Һәр кичебез, һәрбер иртәбез:
«Алтын гасырыбыз кайтыр», – диеп
Өмет баглап гомер итәбез.

Чорлар узар... Утызынчы гасыр
Улларының татар сыманы:
«Алтын гасырыбыз булган», – диеп
Телгә алыр безнең заманны.

**УЛЫМА**

Мин дә, әти, синең эздән барам...

*Рафис Корбан*

Байлыгым юк – юлым кала сиңа,
Юлым кала сиңа бары тик.
Чытырманлы булды минем юлым.
Мин туктадым, ә син ары кит.

Бел син, улым: мин бит язмыш каккан-
Суккан юлларында тормышның,
Канга баткан авыз-борынымны
Учлап, елмаерга тырыштым.

Син дә елмай. Үз юлыңа ялгап
Җибәр минем юлның тәмамын.
Байлыгым юк, юлым кала сиңа.
Синең юлың – минем дәвамым.

**ДОШМАНЫМА РӘХМӘТ ӘЙТӘМ**

Ниятләрен яшермичә
Янап торды дошманым;
Ә дустымның ялганыннан
Чак упкынга очмадым.

Ялгышыма дәшми, дустым
Күпме зыян эшләде!
Ә дошманым бер хатамны
Кичермәде – тешләде.

Рәхмәт инде дошманыма:
Бирде генә кирәкне!
Кырыс мөгаллимдәй, мине
Ялгышмаска өйрәтте.

Дошманыма куям һәйкәл:
Калкып торсын югары.
Дошманыма рәхмәт әйтәм,
Ә дустыма – юк әле...

**ХИСЛӘР**

Язлар саен мин мәхәббәт көтәм
Уналтысы тулган үсмердәй...

*Рашат Низами*

Кайчак, көзгеләргә күзем төшеп
Яки укып иске хатларны,
Җитте, димен, тукталырга вакыт,
Тугарырга вакыт атларны.

Әй! Ялкындай янып сөйгәннәр дә,
«Болай гына» иңгән чибәрләр дә,
Минсез булыр алда юлыгыз!
Адәм ирешмәслек хыялларым,
Тиле хисләр, бәхил булыгыз!

...Абау! Әллә нинди үҗәтлегем
Кабат коткы сала: кит әле,
Әнә сылуларның иң сылуы
Ерактагы зәңгәр офык булып
Чакырыплар тора бит әле...

**ЮЛ ЭКСПРОМТЫ**

Тиң бар микән җирдә миңа –
Шыр тилегә, юләргә?
Эшләремне эткә ташлап,
Киттем сине үбәргә.

Мәми авыз түгел бит мин
Тик ятып яшь түгәргә:
Чакрымнарны адым итеп,
Барам сине үбәргә.

Ялкынсынган йөрәгемне
Тыеп торыйм ниләргә?
Ерак юлны якын итеп
Килдем сине үбәргә.

Каршы ал!

**ХАТЫННАР**

Хатыннарның холыклары бүтән,
Охшамаган безгә һич. Алар
Мәсхәрәдән, хурлык, изелүдән
Бәхет табып яши алалар.

Бичаралар, димим, киресенчә,
Монда илаһи бер акыл бар:
Ирләр түзми гүргә кергәндә дә,
Чыдап яши бирә хатыннар.

Дөнья кыйммәтләре арасында
Яшәү – алар өчен бердәнбер;
Бәлки, шушы сыйфат аркасында
Җирдә тормыш дәвам итәдер...

## ТРОИЦК КАЛАСЫ

Уй ярында таң шәүләсе уйный,
Таң сәламли Уел буйларын...
Шул таңнарда ерак гасырларга,
Тарихларга оча уйларым.
Тәңрем ихтыяры белән, ахры,
Шәһәребез шулай урнашкан:
Мәчетләргә төшә тәүге нурлар
Алсуланып чыккан кояштан.
Сокландырып бу җиһанның
Фәкыйрен дә, баен да,
Таң нурлары җем-җем итә
Мәчетләрнең аенда.
Таңнар ата, мөэминнәрне өндәп
Тәңребездән иңгән бәхеткә:
Татар тыкрыгыннан, әкбәр әйтеп,
Мөселманнар бара гаеткә.
Чиратлашып мәңге алмашына
Кышкы көртләр, җәйге чәчәкләр.
Изгеләрнең кабер ташларында
Балкып сүнә соңгы шәфәкъләр.
Сокландырып бу җиһанның
Фәкыйрен дә, баен да,
Таң нурлары җем-җем итә
Мәчетләрнең аенда.
Кичке шәфәкъ яулый Уй буйларын,
Моңсулата Уел суларын.
Хак Тәгалә үзе яктыртадыр
Халкыбызның язмыш юлларын:
Изгелеккә Раббым соклана күк,
Гөнаһларга гүя күрсенә, –
Көн башлана Татар тыкрыгыннан,
Татар зиратында көн сүнә...
Сокландырып бу җиһанның
Фәкыйрен дә, баен да,
Таң нурлары җем-җем итә
Мәчетләрнең аенда.

## АҢЛАШУ

Үткәндәге гөнаһларны санап
Битәрләшмик әле һәр эштә.
Син дә, бәгърем, изгеләрдән түгел,
Мин үзем дә түгел фәрештә.

Хисләрнең дә кадерен белү кирәк:
Тирә-якта – рухи сукбайлык.
Назга кытлык арткан бу заманда
Сөешү ул – үзе зур байлык.

## ТОЗСЫЗ ШИГЫРЬ

Язгы иртә. Шигырь укыйм. Тозсыз.
Каным өши һәрбер җөмләдән.
Укып кара, дип үтенгән иде
«Мин шагыйрь!» дип йөргән бер адәм.

Соры гыйбарәләр. Ни яз исе,
Ни карасы җирнең, ни агы.
...Ә бакчада гүзәл газәл булып

Балкып тора шомырт куагы.

**БЕРДӘМЛЕК**

Ничек ныгысын иттифак –
Хет өзгәлән, хет сикер:
Бердәм карар кылыйк дисәк,
Ике татар – биш фикер.

**ТРАДИЦИЯ**

Нинди асыл егетләрнең
Башкайларын ашыйбыз:
Гүргә төртеп керткәч кенә
Күккә чөя башлыйбыз.

**ТАРИХНЫ КЕМ ЯЗА?**

Нинди көчләр сайлый икән
Каһарманның варисын?
Шаһгалиләр язмый микән
Кол Шәрифләр тарихын?

**ТАТАР МӨГАЛЛИМӘСЕ**

Мөгаллимнәр арасында
Ир-ат кими – нишлисең!
Заманыбыз шундыйдыр, дип,
Әллә ни китми исем.

Тәрбия – мөселманлыкның
Иң мөһим тәгълиматы.
Шул тәгълимат үзәгендә –
Татар мөгаллимәсе.

Бу эштә юк бәйрәм көне,
Якшәмбесе, шимбәсе.
Шушы йөкне тартып бара
Татар мөгаллимәсе.

Кайда мәктәп балалары,
Кайда үз гаиләсе?
Барысын да тигез күрә
Татар мөгаллимәсе.

Кичен дәфтәр тикшерәсе,
Көндез дәрес бирәсе...
Көн дә эштә, кич тә эштә
Татар мөгаллимәсе.

Тик барыбер чибәрләрнең
Чибәре, күз тимәсен.
Йолдызлардан өстен күрәм
Татар мөгаллимәсен.

Гөлчирәсе, Луизасы,
Алсуы, Саниясе...
Нур сибеп яшә, акыллым,
Татар мөгаллимәсе!

## БҮГЕНГЕ ХАЛӘТЕМ

Киләчәккә очмый хыялларым,
Үткәннәрдә хәтер казына;
Җырларым да хисләр кайнап түгел,
Уйлар туып кына языла.

Әллә көзге кырау, әллә инде
Йөрәк төбендәге юшкынмы,
Әллә хыялларым җимерелү –
Сүрелдерде шигъри утымны.

Яңарышлар булып язлар килгәч,
Бер кабынып, мин дә дөрләдем,
Ләкин бергә янып йөргәннәрнең
Тиздән сүреләсен белмәдем.

Милләт өчен нинди көрәш барды! –
Алкышлардай иде гасырлар.
...Түләсәгез, көрәшәм, дип, бүген
Сатулаша кайбер «батырлар».

Максат – баю... Алар өчен юктыр
Кылган эшнең агы-карасы.
Шаккатам мин: алар да бит татар,
Алар да бит ана баласы!

Әй, татарым, шуны аңла: синең
Бер Ходайдан башка юк хуҗаң.
Ни кызганыч, тарих күрсәткәнчә,
Һәр халыкта була сатлыкҗан.

Тик бит әле шул маңкортлар гына
Тәшкил итми татар галәмен.
Без дә исән әле! Шыт, хыялым!
Оч, фикерем! Уйна, каләмем!

## ТАТАР

Бар татарның Минтимере, Җәлиле,
Бар аның, ни аяныч, Шаһгалие.

Татарларны зур иткән дә – татар ул,
Татарларны хур иткән дә – татар ул.

## АДӘМ БАЛАСЫ

Хак Тәгалә ихтыяры аша
Килде җиргә адәм баласы.
Тәкъдир кушуынча гына туды
Һәр адымы, һәрбер карашы;
Бирде Ходай аңа өмет, сәләт,
Язмышында якты мәнле эз;
Канлы сугышлардан үткәрсә дә,
Исән итте аны Тәңребез.
Илаһыбыз юмарт булгач, адәм
Хезмәтендә үсте югары;
Бәхет эчеп узды гомер юлын,
Имин булды картлык еллары.
Хәзер инде аңа, шөкер итеп,
Оҗмахларга китеп барасы...

...Соңгы сүзен ләкин: «Алла юк», – дип
Йомгаклады адәм баласы.

## ТАТАРЧА

Рәхәтләнә җаным-тәнем,
«Әллүки»не көйләсәм.
Мин татарча, саф татарча
Җырлыйм, көйлим, сөйләшәм.

Дөнья белән мин татарча
Баглашам һәм аңлашам;
Төрки туганнар булыша,
Әгәр аңлый алмасам.

«Кирәкми», – дип йөз чөергән
Ул бит бары хөрәсән.
Ә мин исә чын татарча
Укыйм, язам, сөйләшәм.

Бар Чиләбе, бар Әстерхан,
Иң яктысы бар – Казан.
Мин казанча, саф татарча
Сөйләшәм, укыйм, язам!

## КЫРЫС ТҮРӘГӘ

Мин гаярь, дип шашма, җаным,
Түрә бит ул – пружинаның
Бер очын тоткан кеше.
Ә пружина – хәтәр чара:
Кыскан саен, арта бара
Кайтарып бәрү көче.

## ТҮРӘЛӘР ӨЧЕН БОРЧЫЛУ

Тәхеттәге түрәләрне мактап,
Бик шауламыйк әле, җәмәгать!
Эшмени бу: киткәннәргә – ләгънәт,
Исәннәрдән, имеш, канәгать.
Алар да бит адәм: күп мактасаң,
Дәүләт кайгыларын ташлыйлар;
Әллә чынлап даһи микән мин, дип,
Көзгеләргә карый башлыйлар.
(Үзебезнең дә бит юмалаудан
Аңыбызны били ялчылык.)
Эшләсеннәр алар, түрәләрне
Мәдхияләр белән борчымыйк!

## ИРЕННӘРЕҢ

Ике тойгы бергә кабынганда,
Корыч эри җирдә, су яна.
Иреннәрең назлап кагылганда,
Тәннәремдә ташкын уяна.

Моң кузгала җанда бер тынгысыз:
Әллә тальян, әллә саз кылы?
Нинди тәмле, нинди тыелгысыз,

Нинди хәтәр ләззәт ташкыны!

Бер ургылган ташкын тынмас бит ул,
Ерагайганда да арабыз.
Иреннәрең... Хозур... Яшәү матур...
Мин галәмгә хуҗа, карагыз!

**ҮЛЕП КАРА**

Кадеремне белмиләр, дип,
Бичара, яшь коясың;
Үлсәм, үкенерсез әле,
Дип тә янап куясың.

Ләкин үләр алдыннан син
Бер утырып уйлап бак:
Бәхилләшкән мәлдә, әйе,
Шаулап алыр тирә-як.

Исемеңне тәмләп чәйнәр
Гайбәткә сусаганнар,
Урам тутырып җыелыр
Күрше-күлән, туганнар;

Талант иде, дип, ике юл
Шигыреңне отарлар,
Бер мышкылдап алырлар да
Җирләгәч онытырлар.

Китсәң, исемең югала,
Калсаң, иҗатың бара.
Ышанмыйсыңмыни миңа?
Алайса үлеп кара.

**СУКРАНАМ**

Бер мизгелдәй выжлап узды яшьлек.
Уйлап баксаң, ни ул? Яз гына.
Шул яздан соң күпме вакыт үтте?
Күп түгел дә кебек, аз гына.

Нинди гайрәт иде йөрәкләрдә!
Хыялларга дөнья тар иде.
«Ни теләсәм, шуны эшли алам»
Дип ышанган көннәр бар иде.

Кырык төштәй кырык апрель узган!
Кайда тормышымның җиңеше?
Тәвәккәлләп эшкә бер тотынсам,
Әвеш-түеш чыга җимеше.

Әле ярый – әгәр башлап булса!
Башлап булмый, шайтан алгыры...
...Тәрәзәмдә тәүлек буе үкси
Соңгы көзнең соры яңгыры.

**АКЫЛ САТАМ**

Көз аенда, ягъни аеруча
Ашкынганда йөрәк яшәргә,
Язларымны искә төшерәм дә
Эндәшәсем килә яшьләргә:
«Форсат тигән саен елмаегыз,
Көлә алган чакта көлегез!
Тормыш язларының, җәйләренең,
Яшь вакытның кадерен белегез!»

**САНИЯГӘ**

Без атлыйбыз. Безнең адымнарны
Язмыш ничек җитез саный, ә?
Гомерләрнең уртасына кадәр
Без дә килеп җиттек, Сания!
Татарларны татар итик диеп
Башланылган иде бу барыш;
Җиңелләрдән булып чыкмады шул
Без тотынган милли яңарыш.
Тик үзгәртеп кора алмасак та
Хыялланган кадәр дөньяны,
Татарлыкка баегандай булды
Урал тауларының көньягы.
Холкың күркәм, үтсәң дә син шактый
Чытырманлы тормыш аркылы.
Син – иҗади дәртле һәм сәләтле,
Итагатьле татар хатыны.
Горур яшә җирдә! Дусларың күп.
Ниятең пакь, юлың ак синең.
Миңа да бит куәт биреп тора
Синең көчең, синең тәэсирең.
Без атлыйбыз әле. Көрәшәбез.
Без һаман да әле яшь, дибез.
Киләчәкне уйлап, хыялланып,
Әй, яшибез әле, яшибез!

**КЫЗЛАР**

Кызлар уза язгы урам буйлап...
Ә без? Әле һаман тиле без.
Моннан бер егерме еллар элек,
Чибәрләрем, кайда идегез?

Сезнең һәрбер кыланышыгызда
Чиктән ашып тора дәртлелек.
Без яшь чакта кызлар бүтән иде:
Әйтик, моннан утыз ел элек...

Хәер, моннан кырык еллар элек
Бүтән иде безгә дә бәя.
Ни аяныч: без картайган саен,
Матур кызлар җирдә күбәя...

**ЭЗЛИМ...**

Илһам тумый. Әллә нәрсә кирәк.
Һәр күргәнен язмый каләмнәр.
Җирдә вакыйгалар тулып ята,
Ә мин сюжет эзлим Галәмнән.

Язар азык эзлим. Янәшәмнең
Күрә белмим агын-карасын.
Төнге күкне болыт капласа да,
Йолдызларга оча карашым.

**ДӨНЬЯ**

Очраштырды очраклылык.
«Утырып кит кунак булып!»
«Юк, вакытның тыгыз мәле,
Соңра сөйләшербез әле...»

«Ашыгасың?» – «Ашыгамын».
«Кайчан күрешербез тагын?»
«Булмый калмас ял көннәре,
Салмак чорлар килер әле...»

Өлгермәдек. Соңгы сукмак.
Ап-ак кәфен. Кара туфрак.
Минем чират. Көт син, яме.
Ипләп сөйләшербез әле...

**«ТАТАР ҖЫРЫ» ФЕСТИВАЛЕ**

Куркытмады безне бураннар да,
Наданнардан яуган каһәр дә –
Өч көн шаулап торды татар җыры
Урыс кайнап торган шәһәрдә.
Йөрәгемне назлый даһи моңнар,
Ә уйларым зарлы һәм ачы:
Бер егерме елдан татар җырын
Табылырмы монда җырлаучы?

**ШИГЪРИЯТНЕҢ ИҢ ЗУРЫ**

Сабыйлар өчен язуы –
Шигъриятнең иң дә зуры.
Балаларга язар өчен
Бирү кирәк бөтен көчең,
Бик тә олы булу кирәк
Һәм җитлеккән булу кирәк.
Андый олуг затлар сирәк.

**МӘМДӘЛ – ИСТАМБУЛ**

Дөньяларны гизеп кайта халык.
Мин дә уйлап куйдым бер мәлдә:
Истамбулда әле булганым юк,
Гомеркәем узды Мәмдәлдә.

Хәер, уфтанмыйм да, үкенмим дә:
Безнең авыл аннан ким мәллә?
Истамбулдан да бит беркемнең дә
Булганы юк әле Мәмдәлдә...

**ТАРИХ**

Бүген, имин һәм болытсыз туып

Торган чорда һәрбер иртәбез,
Без, тарихны китаплардан укып,
Ничек җиңел фикер йөртәбез:

Имеш, борынгылар җәфаланган
Узмыш таба алмый язмыштан;
Хакимнәр дә камил булмаганнар:
Тегесе юньсез, монысы ялгышкан...

Күрә торып ычкындырылган бит
Теге мөмкинлекләр, бу форсат...
...Чорлар, ханнар, ерак бабаларны
Сүгеп, тәнкыйтьләве бик ансат.

Ә үзебез? Әнә кайный дөнья!
Уйлап кына кара син бары:
Күпме гөнаһ, күпме ялгышлыклар
Кыла бүгенге көн ханнары!

Болгар. Алтын Урда. Явыз Иван.
Ленин, Гитлер, тагын ары кит...
Кайтмас булып узып киткән көн дә –
Ул кичәге бүген бары тик.

Терсәкне дә тешләп була, ләкин
Кабатланмый тарих яңадан;
Болгарларга кайтып булмагандай,
Кайтып булмый узган таңга да.

Шигърият һәм гакыл исән чакта,
Корып егылганчы соңгы гөл,
Бүгенгене камил итү кирәк,
Бүгенгене... Әле соң түгел!

**ЮЛДА**

*Т-гә*

Йөрүзәнне узам. Юл кырында
Бар мәһабәт текә бер кыя:
Таш кальгадай үзе, ә башында –
Наратлардан купшы такыя.

Шул кыяга кемдер, әллә гарьдән,
Әллә иләсләнеп шат яздан,
Адәм менәлмәслек биеклеккә
«Бәхетле бул, бәгърем!» дип язган.

Шушы җөмлә актарыплар ташлый
Һәр юлчының фикер-хисләрен.
Минем дә шул йөрәк сызлап куйды:
«Нишләдең син, бәгърем, нишләдең?..»

Гаеплемен, бәхет бираламдым.
Хәзер каршы алам һәр таңны:
«Кичер мине, бәгърем», – диеп, әмма
Беләм: инде соң һәм караңгы.

**ЯЗАСЫ ИДЕ...**

Балалар да үсеп очты юкса...

Ә мин һаман бәргәләнеп яшим,
Гүя диңгездәге йомычка.
Шагыйрь вазифасы газап икән
Җитмеш борчулы бу тормышта.

Төннәр таңга авышканда гына
Дәфтәрләрем белән очрашам;
Язып, китапларда актарынып,
Әй кинәнәм шунда, ичмасам.

Әй куанам – кош тоткандай булам,
Килеп чыкса сүзнең яңасы...
Ләззәтләнеп сүзләр дөньясында,
Язасы да иде, язасы!

## МИҢА ҖИТКӘН...

Тынгы белми адәм: арттырмакчы
Ил данын һәм... илдә үз данын.
Бер мактаулы исем алыр өчен
Кемдер сата хәтта вөҗданын.

Ул коткыга гамьсез минем хисем,
Карап торам шуңа гел читтән:
Ирек Нәгыйм улы дигән исем
Бу тормышта миңа бик җиткән.

Миңа җитә, шигъри юлларыма
Төгәл булып күчсә уй очым,
«Мин әйтергә теләгәнне әйткән», –
Дип укыса һәрбер укучым...

## ТОРМЫШ – БЕРӘҮ

Шушы назлы-үтенечле караш
Сезгә генә булсын дисәгез,
Сөйгән ярыгызны һичкайчан да
Ялгызлыкка дучар итмәгез!

Сөю тулып кайнап торсын өчен
Һәр кичегез, һәрбер иртәгез,
Сөйгән ярыгызны беркайчан да
Ялгызлыкка дучар итмәгез!

Көнләшүләр, шикләнүләр төшеп
Болганмасын өчен чишмәгез,
Дөнья куып, сөйгән ярыгызны
Ялгызлыкка дучар итмәгез!

Тормыш – берәү. Бәлки, анысын да
Ахыргача үтеп бетмәбез...
Сөеп өлгерегез ярыгызны,
Ялгызлыкка дучар итмәгез!

## БӘҺА

Мин үземне зур зат диеп саный алмыйм,
Үз-үземә бераз көлемсерәп карыйм.
Мәҗлесләрдә савыт тотып сөрән салмыйм;
Түрдән түгел, бусагадан урын сайлыйм.

Юк, юк, шыңшып, елап, мескенләнеп йөрмим,
Тик, чынлап та, үз бәямне үлчи белмим.
Әгәр халкым күңелендә калса эзем,
Соң булса да искә алыр милләтем, дим.

## МӘХӘББӘТТӘН СОҢГЫ МӘХӘББӘТ

*Р-гә*

Йөрәкләрне телеп улый җилләр:
Җилләрдә дә әллә җан бармы?
Хыялларым, дәртем һәм хисләрем
Чәчем белән бергә чаларды.

Яз кояшы кебек пәйда булдың
Көз җилләре искән юлымда.
Сизми калдым үзем: хәзер инде
Мин сакчың да синең, колың да.

Шатланыйммы, әллә көенимме?
Ләгънәт димме, әллә мең рәхмәт?
...Әҗәлдән соң килгән яшәү кебек –
Мәхәббәттән соңгы мәхәббәт.

Болытлардан ашып, өр-яңадан...
Күпме түзә алыр бу йөрәк?
...Кирәк түгел, бәгърем, кирәк түгел...
...Юк, кадерлем, кирәк, бик кирәк...

## КИЧЕР

Җирдә һични кызыктырмый иде,
Сиңа бәйләнеше булмаса.
Үзең, сүзең, рухың тормышымның
Эчтәлеге булган лабаса.

...Килеп синең белән сөйләшкәндә
Сизмим, җаным, зират салкынын.
Әле дә җылы миңа синең янда.
Рәхмәт, бәгърем. Кичер, алтыным.

## ТАБИГАТЬ

Болыннарга чыгам яңгырдан соң:
Тәнгә-җанга ләззәт вә сихәт.
Әй, тыңлагыз, кала әсирләре:
Табигатьтә бөтен хакыйкать!

Җәйге алан камиллеккә өнди –
Читтә торсын үгет-нәсихәт...
Әй, сәяси уйнаш ялчылары,
Табигатьтә бөтен хакыйкать!

Туган халкым! Бәхетемне таптым
Синең белән генә мин фәкать...
Әй, адашып арган йөрәккәем!
Табигатьтә икән хакыйкать!

## СИНСЕЗ

Төннәрен уяна идем
Бәхетемнән сискәнеп.
Сизмәгәнмен бит җилләрнең
Кайсы якка искәнен.

Кадерен белмәгәнмен бергә
Каршылаган таңнарның.
Кояшым булгансың – шуны
Синсез калгач аңладым.

Бары кечке шәфәкъларда,
Әллә хак, әллә хата, –
«Әле очрашырбыз» дигән
Сәер фикер юата.

## СИН ЕРАКТА ЧАКТА

*Р-гә*

Син янымда икән, кайгылар да,
Гөнаһлар да чыга исемнән;
Син ерактa чакта газапланам
Әллә нинди гаеп хисеннән.

Үпкәләтмәдемме дигән уем
Көн дә, төн дә бирми һич тынгы:
Очрашканда булмадыммы икән
Артык салкын, артык басынкы?

Ялгызлыгым – мәрхәмәтсез җәза.
Болай җәфалану – нәкъ тәмуг...
...Китим әле, барыйм синең янга,
Юкка уфтанудан мәгънә юк...

## СӨЮ

Кайчак пыскып уза гомер,
Янмый сүнә сөюләр;
Сәбәбен дә аңламаслык:
Кем туң йөрәк, кем юләр?

Кайчак исә, күкрәп килсә,
Мәхәббәт тиң яшенгә...
Кайтсын яшьлек, бергә яшьник,
Хисләреңне яшермә.

Үкенечкә калыр, назлы
Тойгылар булса харап...
Янма бушка, гомер кыска,
Сөю күпкә кыскарак.

## ШИГЫРЬ ЯЗАМ

Шигыремне камил итәр өчен
Бер сүз җитми. Җигеп бөтен көчем,
Барлык белемемне күзаллыйм.
Бер төгәл сүз кирәк: табигатьтә
Бар ул, беләм, ләкин табалмыйм.

Менә таптым, диеп куеп карыйм
Шигъри юлга – моңы бозыла.
Ә йөрәктә язылмаган җырлар
Кайнап, ярдан ашып узына:

Сүзгә сусап, яралырга тора
Касыйдәләр, газәл, мөнәҗәт...
Бердәнбер сүз... төннәр буе эзлим...
Нинди авыр газап...
Ни ләззәт!..

### КӨЗ

Тәрәзәмдә – тыныч, кояшлы көз.
Бакчаларда кызгылт сарылык.
Өрәңгеләр, моңсу көлемсерәп:
«Арыдык шул, – диләр, – арыдык».

Шау чәчәкле болыннарда шашып,
Дөрләп өлгермәдек тә ич, әй!
Яшен кебек яшьнәп китеп барды
Салкын айлар буе көткән җәй.

Көз дә матур, ләкин җәйге ямьгә
Охшамаган инде ул бер дә.
Һәр фасылның үз шатлыгы була,
Хәсрәт кенә уртак гомергә.

### ГОМЕР

Бер мәгънәсез узып китте гомер.
Шуны гына җирдә аңладым:
Шушы тормышымда беркемне дә
Мин бәхетле итә алмадым.

Син чакырдың, ә мин атлый тордым
Белмичә дә кая барасын;
Юньсез тормышымның юл чатында
Басып калды нәүмиз карашың.

Үз-үземә кайчак: «Чакыр, – димен, –
Каерылып кына кара да...»
...Көзләр-кышлар ята араларда,
Айлар-еллар ята арада...

### КИТТЕҢ

Чыгып киттең. Көз. Караңгы.
Гарьлек. Иртәнге алты.
Тышта суык. Эчтә бушлык.
Киттең. Ачкычың калды.

Авыр сүзләр. Киттең. Суык.
Йөрәк зардан ял сорый.
Көз. Таң алды. Ай яктысы.
Киттең. Ачкыч ялтырый...

**КИНӘТ**

Чынлап тамы әллә, чынлап тамы
Җилгә очкан үпкән-кочканнар?
Ун ел буе сөеп-сөештек тә,
Кинәт кенә булдык дошманнар.

Юкка булганмыни синең белән
Зәңгәр киңлекләрдә очканым?
Мин сиңа ни – белмим, ә син минем
Иң кадерле газиз «дошманым».

**МАКСАТ**

Хак Тәгалә җиргә ник яраткан
Ирек дигән фәкыйрь бер затын?
Серле, табышмаклы бу дөньяда
Нигә яшим, нидә максатым?

Бәхет өчен, дисәм, ни ул бәхет?
Ул – бары тик татлы буш хыял.
Бәхет эзләп йөреп, тормышыңны
Сизми калуың да ихтимал.

Олыгаеп беттем. Җавап килде.
Хафаланмыйм хәзер мин бер дә:
Гомеремнең төп максаты – яшәү.
Яшәү өчен яшим мин җирдә.

**КИЛӘМ**

*Р-гә*

Нәрсә әйттең, иркәм? Ишетмәдем.
Әй аралар бигрәк ерак ла.
Киләм!.. Килеп кочагыма алгач,
Күзләремә карап кабатла.

Дөнья якты димен!.. Ишетмисең
Сызгыруы аша җилләрнең.
Киләм!.. Килеп, чәчләреңнән үбеп,
Шатлыгымны сиңа сөйләрмен.

Йөрәккәем сызлый. Ләкин, килгәч,
Тилмертмәмен сине яшь түгеп:
Кулларыңны учлап елмаермын,
Зарларымны синнән яшереп.

Нәрсә әйттең, бәгърем?.. Арабызда
Гасыр ята микән? Ел? Атна?
Зарыктымы кайнар иреннәрең?
Килдем!.. Әйткәнеңне кабатла.

**БУРЫЧЛАР**

Кинә саклап китмим мин тормыштан:
Һичберегезнең дә, и дуслар,
Бурычы юк миңа. Үземнең дә
Кайтарылган бөтен бурычлар.

Хәер... Бәгърем, язмышымда сине

Биргән өчен шөкер Тәңремә.
Бурычлымын сиңа. Ул бурычым
Кайтарырлык түгел мәңге дә.

**ГАИЛӘБЕЗ**

Сабый елларымның иң зур яме –
Ишле гаиләбез.
Ике абый, өч апам һәм сеңлем –
Изге даирәбез.

Шунда минем әхлак нигезем һәм
Хезмәт башлангычым,
Шуңа җиңеп барам яшәешнең
Хәсрәт вә сагышын.

Әти киңәшләре, әни назы –
Мәңге кипмәс чишмә.
Барыбызны җыйган аш-табыннар
Әле дә керә төшкә.

Җидебезнең дә шул иң кадерле
Уртак хатирәбез –
Көр холыклы, тату, мәхәббәтле
Эшчән гаиләбез.

**АЛАР ҺӘМ БЕЗ**

Борын заман шагыйрьләре, имеш,
Нинди даһи, нинди асыллар;
Римлыларны гына укып кара:
Горацийлар, Тибулл, Катуллар...

Ләкин шанлы исемнәрне ятлап
Шаккатма син ятка, якташым.
Бездә Горацийлар булмагандай,
Римның да бит юктыр Такташы...

**ЯЗ АЕ**

Илле яшем тулып авышканда,
Хәтерләтеп егет чагымны,
Йөрәгемнең тирән бер түрендә
Әллә нинди чаткы кабынды.

Машинамда барам. Очасылар
Килә шушы гаҗәп чаткыдан:
«Яшел жилетлылар» күрмәгәндә,
Йөз егерме белән чаптырам.

Юл читендә – кызлар... Чибәрләрем,
Әйдә, йолдызларга барабыз!
Тик мин бүген сезгә абый түгел,
Сизелми бит болай арабыз.

Көзнең усал җиле дуласа да,
Күңелемдә һаман яз ае...
Чөнки бит мин татар токымыннан,
Нәгыйм улы, Мәмдәл малае!..

## КЕМГӘ ХАТ ЯЗЫЙМ?

Чиктән ашты вакыт тизләнеше:
Иртән – бәби туе, кич – ясин...
Уй-хисләрем кайный. Кемгә сөйлим?
Бер утырып кемгә хат язым?

Телсез дөнья! Тамга, ымнар чоры.
Яхшымы бу, белмим, яманмы?
Кире кайтмас шигъри дәвер булып
Артта калган хатлар заманы.

Әңгәмәдәш тапмаганнан шашып
(Кем елмаер безгә, кем елар?),
Йөрәгемне талый, эчтән ашый
Ялкынсынган фикер-тойгылар.

Дуслар дисәм, ниятләре фани
Ихтыяҗлар белән чикләнгән;
Һәрберсенең йөзе битараф та,
Һәммәсенең җаны бикләнгән.

...Гыйнвар көртләрендә әллә кояш,
Әллә узган гасыр чагыла?
...Кышкы төннәр буе хатлар язам
Мин үземнең малай чагыма.

## БАЙЛЫК ҺӘМ БӘХЕТ

Үзе баеп киткәч, дустым
Дәште мине кунакка.
«Шулмы бәхтең?» – дип сорадым,
Кергәч затлы пулатка.
Күзгә туры бакмый гына
Бирде дустым җавабын:
«Әле тагын «Лексус»ым бар,
«Мерседес»ым, «Сааб»ым...»
Ә мин кабат сорыйм, карап
Оҗмахка тиң табынга:
«Ирештеңме бәхетеңә?
Җиттеңме морадыңа?»
Аның исә тавышында
Әллә үпкә, әллә зар:
«Бер йорт салдым Майамида,
Парижда да виллам бар...»
...Үзе шунда бозау хәтле
Этен сөя: «Кечкенәм...»
Мин һаман бәхет хакында
Төпченәм дә төпченәм.
Минем мондый үҗәтлектән
Булгач тәмам да гарык,
Үксеп елап җибәрде ул,
Күкрәгемә капланып...

## ӨЕБЕЗДӘ

Тәрәзәдән керә урам шавы:
Анда низаг, анда талашу...
Өебездә исә җылы, бәгърем,
Язгы судай бездә хис ташу.
Булды көннәр – без дә ул шаукымнан,

Ул шашудан читтә калмадык;
Кайнар нотык сөйләп, үзебез дә
Аңламаган бәхет дауладык.
Әйтер сүзне әйттек. Кил яныма.
Безнең өйдә – бүтән замана.
Тәрәзәдән шау-шу керә димсең?
Алар милек бүлә. Карама.

**КЕМ ГАЕПЛЕ?**

Русьны харап иткән гаеплене
Тарихлардан эзләп табалар:
Патшаларны, сәвитләрне сүгеп,
Татарны да искә алалар.
Эзлисе юк, моны аңлар өчен
Кирәк түгел кебек зур акыл:
Илне бәреп еккан ул залимнең,
Ул иблиснең аты – Аракы.
Килер бер көн (ялгышасым килә,
Мин таныргга әзер хатамны) –
Чираттагы бер махмырдан айнып,
Табалмабыз җирдә Ватанны...

**КӨЗГЕ ЭТЮД**

Көз кояшы ялый күкрәгемне.
Җәйне инде бары сагынмы?
Вәгъдәләр дә бетте, дәгъвалар да...
Үзем исә – чал һәм ягымлы.
Эңгер төште кебек: көнкүрешнең
Әллә кая качты ямь-рәте;
Хатирәләр арта барган саен
Кими хыяллану ләззәте.
Кичәге көн ачык китап булса,
Бүгенгене читен аңлавы.
Сөю кояшлары баеп бара,
Атып килә хәсрәт таңнары.
...Тик бер татар кызы узган мәлдә –
Кара әле, нинди маладис! –
Томырылып карап калам ич...
Йөрәгемне талпындырып ала
Онытыла язган наян хис.

**ИКЕ АВАЗ**

Истә генә калды кояшлы яз,
Һаваларда – кошлар кыйгачы.
...Без аерым чакта –
ике ялгыз аваз,
Бергә чакта – моңлы көй башы.

**ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ ТҮРӘЛӘР**

Кемнәр генә менми тәхетләргә!
Тик, булса да заман бик мастер,
Шагыйрьләрне түрә итеп була,
Түрәләрдән шагыйрь чыкмастыр.

**ТОРМЫШ ЯМЕ**

Сату-алу, исәп-хисап,
Дан, хакимлек, мал-милек...
Син яшисең, бу дөньяга
Мәңгегә килгән кебек.
«Яшәү мәгънәсе шул», – диеп
Юатасың үзеңне.
Әмма, дускай, киңрәк итеп
Ачып кара күзеңне:
Гомер кыска, дөнья фани,
Егыла гөлләр, сулып.
Тормыш узар, тәннәр тузар,
Мөлкәт очар көл булып.
Фәлән елдан онытылыр
Эшең, даның, кадерең,
Фәлән елдан тигезләнеп,
Юкка чыгар каберең.
Минем исә мәхәббәт һәм
Сафлык – җаным кәгъбәсе:
Шунда гына тормыш яме,
Шунда гына мәгънәсе.

**ЯЗ ҺӘМ КӨЗ**

Киләчәкнең шатлык-хәсрәтләре
Якты хыялыма язылган.
Якынлашып килгән көзем миңа
Кадерлерәк узган язымнан.

*** * ***

*Салисә Гәрәевага*

Монда шыткан милли эшләр –
Аның изге эше ул.
Һәр татарга: «Син татар!» – дип
Тукып торган кеше ул.
Хәзер исә сирәк кенә
Килеп тора хатлары.
...Ул – Уралның Казандагы
Иң мактаулы татары.

*** * ***

*Ф-га*

Әй җырлыйсың тыпырдап та,
Җиңнәреңне болгап та:
Әйтерсең лә гашыйк үзең
Гармунчыга чынлап та.
Ник инженер булып йөрим,
Ник гармунчы түгел мин?
Яннарыңда уйнар идем
Сәхнәләрдә бүген, дим.
Дикъкатеңне тик үземә
Итәр идем мин җәлеп...
Ник заводта эшләп йөрим
Еллар буе этләнеп?

**МӘДХИЯ**

Яз җылысы бирдең, рәхмәт Сиңа!
Өмет бөркеп янды күкләрең;
Тәүге яшен булып балкыдың да
Уңыш вәгъдә итеп күкрәдең.

Рәхмәт Сиңа, яз ләззәте бирдең.
Әмма, Раббым, үзең беләсең:
Рәхмәт укып көттем мин җиһанның
Һәр суыгын, һәрбер чилләсен.

Һәр шатлыгын. Ә кайгылар килсә,
Күрми икән мине, димәдем;
Синнән генә көттем ярлыкауны,
Бүтәннәргә башым имәдем.

...Кояшкаем байый. Тик мин беләм
Таңнарыңның якты буласын.
Киләчәгем мәңге Синең белән,
Рәхмәт Сиңа, рәхмәт, Илаһым!

**ӘТИЕМ КАБЕРЕ ЯНЫНДА**

**1**

Килгән саен көям, карап
Зират миләшләренә.
Синсез яшәп, бик сусадым
Синең киңәшләреңә.
Монда тынлык. Тик миләшләр
Елап шыңшый зар көен;
Күрешүләр мөмкин түгел,
Әмма нишлим, әтием,
Рухым сиңа тартыла шул.
Бүген тагын түзмәдем:
Калгандыр, дим, йөрәгеңдә
Әйтелмәгән сүзләрең.
Кабат килеп, көннәремне
Синең янда уздырам;
Уйларымны сиңа сөйләп,
Сине тыңлап утырам.

**2**

Без үскәндә вәгазь кылып тордың,
Сүз җебеңне башлап ерактан:
«Татармы син, русмы – һәммәбезне
Хак Тәгалә тигез яраткан.
Тигезлеккә өнди илебездә
Күрсәтмәләр, закон-кануннар...»
...Аһ, әтием, үзем сиздем: бездә
Язылмаган күпме канун бар.
Тугры булдым сиңа, шуңа микән
Һәр бәндәне җирдә дус иттем;
Ярсып сөйдем Рәсәй кырларында
Һәр үләннең, гөлнең хуш исен.
Үземне дә үз иттеләр бугай, –
Дусларга бай якын-тирәләр;
«Басурман», – дип, күзгә туры карап
Сүкмәделәр мине түрәләр.
Әмма никтер серле рәвешләрдә

(Аңлап микән, әллә ничекме?..)
«Өлкән агайларым» ябып торды
Керим дигән һәрбер ишекне.
Әти, әти! Нык булса да минем
Синнән күчкән холык-җисемем,
Киртә булды язмыш юлларымда
Син куштырган матур исемем.
Тамырымны истә тотып уздым
Тормышымда һәрбер мизгелне,
Шуңа, ахры, явыз канун рухы
Һәр адымда үзен сиздерде.
Рәхмәт сиңа, әти, үстергәнсең
Киң күңелле итеп улыңны;
Шуңа күрә явыз бәндәләргә
Үчләнүдән өстен булдыммы?
Бүген дә шул, йөрәгемне назлап,
Тавыш килә синең тарафтан:
«Дус яшәгез җирдә. Хак Тәгалә
Һәммәбезне тигез яраткан...»

**3**

Әйтә идең: «Чабышмагыз,
Тулсын диеп кесәбез;
Һөнәр белеп, җырлар сөеп,
Китап укып яшәгез.
Мал муллыгы – фани байлык,
Рух байлыгы – чын байлык...»
...Аһ, этием, бигрәк бүтән
Бүген безнең чынбарлык.
Һөнәр сөйсәң – шыр тиле син,
Шигырь сөйсәң – хөрәсән;
Син килмешәк бу тормышта,
Сатулаша белмәсәң.
Вөҗдан дисәң, – исәр мәхлук,
Хәйлә белсәң – рас галим;
Китаплылар – ачлы-туклы,
Хисапчылар – господин.
...Тик шулай да хаклыгыңа
Мин ышанам, этием.
Юк байлыгым, ләкин дөньям
Хәзинәгә бай минем:
Бар дөньямда синең акыл,
Тарих дәресләре бар,
Тукай теле, Тукай җыры,
Тукай варислары бар.
Сафлык сөеп, язлар көтеп
Уза минем көннәрем;
Синең эзләреңнән атлыйм,
Тугры сиңа йөрәгем.

**4**

Ничәнчедер тапкыр
Бәреп екты язмыш.
Янды тәнем, акты яшьләрем.
Түздем. Миңа дошман кулы таныш, –
Шәфкать сорап бер сүз дәшмәдем.
Бусы да бит, әти,
Синең васыять, –
Мин тәкрарлыйм кочып ташыңны:
«Егылсаң да бетеп хәл-куәтең,
Залимнәргә имә башыңны».

Ничә тапкыр миңа,
Сүнәм дигән мәлдә,
Фаразымда: «Ян!» — дип эндәштең;
Ничә тапкыр упкын чикләрендә
Терәк булды миңа киңәшең!
Ничә тапкыр сынып,
Янә торып бастым.
...Килер бер көн – бәлки, торалмам.
Тик, әтием, йокың тыныч булсын,
Залимнәргә барып соранмам.

**ҖӘЛИЛ СУРӘТЕ**

Сабый чакның кайбер мизгелләре
Еллар буе китми башымнан.
Сүз чыкканда, безгә кырын карап
Пышылдады зурлар: «Сатылган...»

Әллә нинди хаста үтеп керде
Яшь җаныма шушы сүзләрдән:
«Исән икән... «Теге як»та яши...
Яшеренә... Исемен үзгәрткән...»

Әмма тиздән тарих гаделлеге
Бик гыйбрәтле сабак өйрәтте.
Хәтеремдә: Указ. Журнал бите.
Алтын Йолдыз. Җәлил сурәте.

Еллар узды. Тәкъдиркәем мине
Анда бәреп, монда ыргытты.
Бу дөньяның явыз утларыннан,
Ачыш ясап, таптым чынлыкны.

Без бит иң-иң батыр егетләрне
Сау башлары белән түгел лә,
Гүр ташлары белән саныйбыз.
Туксан тугыз канлы газап аша
Үтсәң генә сине таныйбыз.

Күпме булса дәртең, шулкадәрле
Хәтәр оча дошман уклары.
Пакь йөрәкле адәм баласының
Авыр була тормыш сукмагы.

Без үзебез аңламаган эшне
«Ап-ак җирдә шакшы тап» дибез,
Әүвәл бәреп егып таптыйбыз да
Соңра күккә чөеп мактыйбыз.

Кардәшләрем! Ә без бүген менә
Аңлыйбызмы тарих гыйбрәтен?
Кичер, Җәлил! Чыкмый хәтеремнән
Иске журнал битләрендә күргән
«Җырларым» һәм якты сурәтең...

**ҮСЕП ҖИТТЕҢ, УЛЫМ**

Тук үстек без. Ләкин әниебез
Күп сөйләде узган чор гарен;

Ач елларда язгы басуларда
Күкәриннәр җыеп йөргәнен.

«Тишек башмак бата былчыракка,
Персидәтел артта сүгенә...
Калса да шул еллар бик еракта,
Онытмагыз аны бүген дә».

...Үсеп җиттең, улым. Күңел әрни:
Бурычларны ничек түләргә?
Дәү әниең әйткән гыйбрәтләрне
Онытканмын сиңа сөйләргә.

Син шул кыйссалардан мәхрүм булдың,
Язмыш сиңа булды мөлаем,
«Монтана»лы чалбар кигән балам,
Рэп-рок тыңлап үскән малаем!

Дөрес, ипле синең нигезләрең,
Саф йөрәгең, менә шуңа да
Каным синдә үзе уяныр дип
Өметләнеп яшим дөньяда.

Килер бер көн – тартыр тамырларың,
Туйдырырлар сине ят җырлар;
Бер гүзәл моң булып хәтереңдә
Уянырлар узган гасырлар.

**МӘТРҮШКӘЛЕ ЧӘЙ**

Мәтрүшкәле чәйләр эчеп алыйк,
Алан уртасында җәелеп.
Чәйләр белән тәмен татып калыйк
Бу бик кыска Урал җәенең.

Нидер сөйли җилгә назлы каен,
Толымнары бигрәк сөйкемле.
Каенкаем! Сине күргән саен,
Яшьлегемә кайтам шикелле.

Казан каеннары чакырса да
Ерак почмагыннан хәтернең,
Яшьлеккә дә, туган якларга да
Кайтып булмас, ахры, кадерлем.

Менә шулай җәйге аланнарда
Мәтрүшкәле чәйләр эчәрбез;
Туган-үскән илгә кайталмагач,
Торган җирне туган итәрбез.

**ТУФАН**

Кемнәр аңлап, кемнәр аңламыйча
Куандылар ирек җиленә.
Канга баткан йөрәккәен учлап,
Туфан кайтты туган иленә.

Ул ялкындай дөрләде дә сүнде.
Ә без исә, малай-шалайлар,
Туфаннарның өметен акламадык,

Азатлыкның кадерен сакламадык,
Каберләрне таптап, корып салдык
Алтын рәшәткәле сарайлар.

Алтын читлек рәхәт бирми җанга,
Асыл чорны күңел сагына.
Туфан сөйгән, Туфан гизгән күктә
Агыла да болыт, агыла...

**БИК ЕРАКТА**

Бик еракта, бик еракта
Ослан тавы, Кабан күле;
Ямьле фигыль, саф җөмләле
Тукай җыры, Такташ теле.

Зур хакыйкать, күп белемнәр
Алдым күрше рус теленнән.
Мин яхшырак беләм аны
Русларның да бик күбеннән.

Ләкин кайчак тын кичләрдә
Кинәт калка уй-хатирә:
Әллә әрләп, әллә җәлләп,
Таныш җырның моңы килә.

«Галиябану, сылуым-иркәм...»
...Истәлекләр – зәңгәр җилкән,
Урал кичеп кайтып керсәм,
Авылым мине таныр микән?

«Каз канаты ап-ак була...»
...Чигәләргә чаллар куна,
Дәвалар юк, дарулар юк
Күңелләрем сызлануга.

«Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный...»
...Кайтсам да шул Мәмдәлемә,
Яшьлегемә кайтып булмый.

Илебез зур, һөнәрләр күп:
Кемгә – табыш, кемгә – сагыз.
Бәхет эзләп, мавыгып йөреп,
Тамырларны онытмагыз.
Онытмагыз, онытмагыз
Туган болыннарның җилен,
Ямьле фигыль, саф җөмләле
Тукай җырын, Такташ телен...

**КАЗАНДА КУНАКТА**

Өрәңгеләр монда яфрак ярган,
Бездә шәрә әле каеннар.
Аһ, Казаным! Синдә – кояш. Ләкин
Йөрәгемдә синә зарым бар.

Синдә – язлар, бездә – суык әле.
Синдә – якты, бездә – караңгы.
Әйт, Казаным, ничек татар итеп
Үстерим мин газиз баламны?

Синдә – гыйлем. Бездә – рухи ачлык.
Чирли татар, булмый терелтеп.
Җыелганда бергә, аңлашабыз
Ике ярым телне бер итеп.

Шатлан язга, Казан! Тик аяныч
(Аңлашылыр микән уйларым?) –
Таулар артындагы улларыңа
Барып җитми синең нурларың.

**ИКЕ ҖӘЗА**

Туган якны хәтерләтә һәр таң,
Бергә йөргән тавын-үзәнен.
Җәйге таңда яңгыр булып яусам,
Танырсыңмы мине, гүзәлем?

Йөрдек бергә кызгылт урманнарда,
Сөеп өрәңгеләр ялкынын.
Көзге яфрак булып балкыганда,
Танырсыңмы мине, алтыным?

Без куанган идек карлы көнгә,
Бәхетләрнең теләп иң зурын.
Карлар булып кунсам керфегеңә,
Танырсыңмы мине, күз нурым?

Гөлгә чума иде язын бакчаң,
Шул бакчага оча уйларым.
Түтәлеңдә чәчәк булып атсам,
Танырсыңмы, язгы хыялым?

Ике җәза бирде миңа язмыш,
Өзә алмыйм тәкъдир богавын.
Берсе аның – кавыша алмавыбыз,
Икенчесе – оныта алмавым.

**ҮЗГӘРМӘГӘН**

Үзгәрмәгән, ахры, җисемем минем:
Тагын миңгерәтте яз җиле.
Элгәре мин яшь һәм юләр идем,
Бүген исә карт һәм шыр тиле.

**ГӨЛӘП**

Коелса да гөләп чәчәкләре,
Хуш ис калган бераз куакта.
Без дә шулай: калган кебек назың,
Булсаң да син үзең еракта.

Алып китте соңгы хуш исләрне
Җәй җилләре. Саргайды хатлар.
Өметләрем янды. Килеп җитте
Әрем чәчәк атар вакытлар.

**КӨЗ БАШЫ**

Хәсрәт килгән кебек көтмәгәндә
Җан тетрәтеп килде көз башы;
Күл ярына барып йөрсәм дә шул,
Сагыш кына минем юлдашым.

Ни булды бу? Якты болыннарда
Әллә үзем генә йөрдемме?
Эссе җәйнең кайнар мизгелләрен
Төшләремдә генә күрдемме?

Бәхетемнең татлы валчыклары
Комга әверелеп суынды.
Саташулы уйларымда гына
Учларымда тоям кулыңны.

Бугазымны буган төер кебек,
Көз җилләре кыса тынымны...
Ник ашыктың, нигә тыңламадың
Соңга кадәр минем җырымны?

Көз көз инде. Алтын дисәләр дә,
Синең карашыңдай салкын ул.
Язлар кайткач, назлар кайтыр микән,
Насыйп микән кабат талпыну?

Алсулана офык, янган кебек
Шәфәкъләры җәйге кичләрнең.
Эзләрең юк. Комда эзләр калмый.
Ә йөрәктә калса, нишләрмен?

Монда тынлык. Гүя җәйге хисләр
Дөнья куеп, комга күмелгән.
Күл ярының җырлы, серле дәрте
Җәй чилләсе белән сүрелгән.
Аргы якта ялгыз учак яна,
Хәтерләтеп ләззәт көннәрен.
Бирге якта исә җил туздыра
Учагымның суык көлләрен.

...Бугазымны буган төен кебек,
Көз җилләре кыса тынымны.
Туңам бүген, бәгърем, сиңа бирдем
Йөрәктәге бөтен җылымны.

## ҮПКӘЛӘШКӘЧ

Керсәң төшемә елмаеп,
Әй куанам уянып!
Шук сүземне, сәбәп табып,
Булмасмы кире алып?
Дуамаллык, юләрлекнең
Кайда булды чикләре?
Авыр сүзне әйтмәс өчен
Ихтыярым җитмәде.
Үз-үземә: «Назлап сөй, – дим, –
Кайда синең җан зурлык?»
Ә күңелдә – әллә нинди
Таштай каткан горурлык.
Нигә кирәк бу мәсхәрә,
Чиста суда болганыч?
Төштә генә ләззәтләнәм,
Төштә генә юаныч.

...Шулай уфтанып йөргәндә
Елмаеп куйдың, иркәм.
Мин күргән төшләрне әллә
Син дә күргәнсең микән?

**ЯЗ**

Алып китте апрель йөрәгемнән
Сагыш дигән ачы сагызны;
Кыш тудырган суык уйларымны
Яз кояшы эретеп агызды.

Керфегемдә тамчы җемелдиме?
Димәк, рухым гарьдән арына;
Бозлы җилдә туңып каткан күңелем
«Яшим!» диеп канат кагына...

**КӨНЛӘШҮЕМ – СӨЮДӘН**

Хыянәт ул – кыямәт ул,
Аның тәмен беләм мин;
Шуңа аны дуска түгел,
Дошманга да теләмим.

Синсез үтсә бер сәгатем,
Шөбһәләнәм шул, иркәм:
«Алай микән, болай микән,
Әллә тегеләй микән?»

Көнләшәсең, дип рәнҗемә,
Көнләшүем – сөюдән,
Минем өчен җирдә синсез
Бәхет югын белүдән.

Көн буена фаразлаган
Уйларым чынга ашса,
Тулган иреннәрең белән
Иреннәрем очрашса,
Төнге күктә кояш калка,
Күзен шыта бөреләр,
Булыр-булмас гөнаһларың
Кичерелеп эриләр.

Йөзләреңдә – алсу шәфәкъ,
Күзләреңдә – таң гына,
Дулкыннарың, миңа күчеп,
Күкрәгемне яндыра.

...Тәнемнең һәр күзәнәге
Сине тойган чакларда,
Көнләшмим дә, шикләнмим дә,
Ышанмыйм да юк-барга...

**КАЙДА БУЛДЫ УЙЛАРЫҢ?**

Бердәнберем, назлы ярым,
Таңнарымның былбылы!
Күңелләрең, хыялларың

Миндә генә булдымы?

Йөрәгеңнең тибешләрен
Тойган чакта кулларым,
Кайда булды фаразларың,
Кемдә булды уйларың?

Сизгән чакта йөрәккәем
Карашыңның утларын,
Уйларыңны белмәгәем,
Диеп оча котларым...

## ОЗАТУ

Тагын сине озатырга бардым
Шаулы мәйданына вокзалның.
Иреннәрең тәме – иренемдә,
Үзең ашыгып күздән югалдың.

Ләззәт минутларын озайтырга
Сәбәп тапмый тагын тилмердем.
«Китмә», – диде күңелем,
«Сау бул», – диде телем;
Бәхет нурын үзем сүндердем.

Әйтер сүзем тагын әйтелмәде,
Кемгә кирәк булды бу түзем?
Мәйдан шау-шуында юкка чыктың,
Иләсләнеп калдым берүзем.

## КӨЗ

Шыгыр-шыгыр диеп ыңгыраша
Ял паркында ялгыз бер таган.
Көзнең сары каен яфраклары
Чал чәчемә минем охшаган.

Мәктәп болдырында – үсмер яшьләр,
Күзләрендә – тормыш ләззәте.
Шуңадырмы бигрәк мәрхәмәтсез
Талый мине шиңү хәсрәте.

Килер көннәр, яшел каеннарның
Толымнарын назлап тарар яз.
Яшьлек төсе керер табигатькә.
...Минем чәчләр генә каралмас.

## ХЫЯЛЛАР

Яшьлегемдә корган мең хыялның
Аштырдыммы чынга тик берен?
Язгы өмет белән көзге чынлык
Арасында калды гомерем.

Ә нигә соң әле бүген дә мин
Хыялланып тагын шатланам?
Яз үтмәгән, ахры, көз җитмәгән,
Болыт кына күкне каплаган.

## МИНЕМ ИСӘ...

Куанасың бүген иркенлеккә,
Торгын еллар зарын хәтерләп.
Язганыңны өстәл тартмасында
Саклап яшәгәнсең кадерләп.

Минем исә шәрә өстәлләрем.
Соры еллар, рухи ярлылар
Аягымнан бәреп ектылар да
Каләмемне тартып алдылар...

## ЯШИМ

Күнеккән хәл инде: бирде язмыш
Борыч белән бутап балларны...
Киткән җирдә беркем озатмады,
Кайттым – һичкем каршы алмады.

Гомер буе бер хакыйкать ятлыйм:
Тегендә дә ят мин, монда да.
Тик шулай да яшим әле, яшим,
Өмет корып яшим дөньяда.

## АЕРЫЛЫШУ

Хөкем узган. Карар – кулда.
Үпкәләпме язмышка,
Нидер көткән кебек, икәү
Чыгып баскан баскычка.

Еллар буе бергә яшәп
Күптән кушылган каннар.
Кичә бер җан иде алар,
Бүген аерылышканнар.

Яз таңында туган хисләр
Туңып шиңгәнме кышта?
Хатын – чибәр, ир – мәһабәт,
Ни җитмәгән тормышта?

Ике йөрәк, чирдән айнып,
Аптыраган гүяки.
И дусларым, кочаклашып
Үбешерсездер, бәлки?
Онытыгыз вак-төякне,
Ачуларны, зарларны;
Хәтерләгез бергә сайрап
Каршылаган таңнарны.

Юк, булмады инде. Хәтта
Кысмады да кул кулны.
Җәрәхәтле ике йөрәк
Ике якка омтылды.

Нинди хисләр кичергәндер
Кара янган бу җаннар?
Кичә бергә иде алар,
Бүген аерылышканнар.

### ҖӘЙДӘ ЯШЬНӘП...

Сибелә чәчәк, сибелә чәчәк,
Сибелә чәчәк – күз микән?
Язда гөрләп, җәйдә яшьнәп
Яшәгәннәр без микән?

Ком бураны, ком бураны,
Күз ачырмый дулады.
Язлар акты, җәйләр янды,
Нәүмиз ярлар елады.

Тал әйләнә, тал әйләнә
Очып китәрдәй булып;
Газиз яшьлегем, килсәнә
Көз артыннан җәй булып.

Әй гөлбакча, әй гөлбакча,
Кара кашлар, ал ирен.
Яшьлегебез кире кайтса,
Белер идек кадерен...

### КАЙДА МӘГЪНӘ?

Баер өчен яшисеңме җирдә,
Әллә яшәр өчен байыйсың?
Әллә баюың да, яшәвең дә
Бу җиһанның бер зур кайгысын
Юк итәргә сиңа юл ачамы?
Иҗат ireклеге бирәме?
Йә ниятең тоташ гөлбакчалы
Итәргәме якын-тирәңне?
Әйтик, алтын сарай салдырырсың,
Җыеп бөтен дөнья акчасын...
Ә аннары нәрсә? Кайда кыйблаң?
Кайда мәгънә? Кайда максатың?

### БЕЛЕП ТОРГАН ИДЕК

Көз киләсен җәй буена
Белеп торган идек шул,
Тик шулай да ун гомерлек
Хыял корган идек шул.

Хәлләр бетте, дәртләр сүнде,
Кайнар көннәр сүрелде;
Яфракларның – сарылары,
Чәчнең чалы күренде.

Минем талган йөрәгем дә
Әллә инде ял сорый?
...Күлнең шадра көзгесендә
Шәрә таллар калтырый.

### КИЧЕРДЕҢМЕ ИКӘН?

Әниемнең моңлы кыйссаларын
Ишеткәндәй булам саташып;
Төшләремдә йөрим туган өйнең
Каралтыларында адашып.
Бик җентекләп нидер сораштырам

Баз артында үскән зелпедән;
Хәтеремнең шомлы эңгерендә
Әллә кемне эзләп интегәм.

Менә кайттым. Дәшми каберең.
Кичерденме икән, бәгырем?

Рәнҗетмәдем кебек үскән чакта,
Итагатьле идем, ягымлы;
Әмма әллә нинди гөнаһ хисе
Гомер буе талый җанымны.
Рәнҗегәндәй булган мизгелләрең
Искә төшә тагын, тагын да.
Соңгы сулышыңда чакыргансың,–
Була алмадым шул яныңда.

Әнием, кайттым!.. Дәшми каберең.
Кичерденме икән, бәгырем?

## СОҢАРГАН МӘХӘББӘТ

Ялкыннарга төрдең чал башымны.
Ышанучан йомшак карашыңны,
Очрашмаган булсак та без элек,
Таныгандай булдым бер күреп.

Җәйләр узган, җиткән көзнең сагышлары,
Салмакланган тормышларның агышлары.

Нигә очрамадың яшьлегемдә,
Мәмдәлемдә, Идел ярларында?
Гомер буе сине сагынганмын,
Бер гомергә соңга калганмын.

Узды тормышның югалту-табышлары,
Йөрәкләрне өзә сулу сагышлары.

Тәүге тапкыр күреп саф йөзеңне,
Таныгандай булдым яшьлегемне.
Син янымда бүген, янәшәмдә,
Ә яшьлегем – ерак җәйләрдә.

Узган җәйләр, җиткән көзнең сагышлары,
Салмакланган тормышларның агышлары.

## САРЫКҮЛ

Көзге җилләр, дымлы җилләр
Тиң булганга җаныма,
Томан ярып чыгам иртән
Сарыкүлнең ярына.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

Соры камыш. Ялгыз аккош.
Синсез тормыш – коры чүл.
Минем хисләремдәй моңсу
Сагыш күле – Сарыкүл.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

Арабызда – Урал тавы.
Ятим калдык кебек без.
Сарыкүлнең томаныдай
Киләчәкләр өметсез.

Ялгызлыкта, нәүмизлектә
Көн артыннан көн ага.
Кайгыларсыз гына яшәп
Булмыймыни дөньяда?

**ХАТЛАР КӨТӘМ**

Күпме яшәп җирдә, шуннан тәмле,
Шуннан ачы шөгыль тапмадым.
Кабат укыйм мәрхүм әтиемнең
Саргаеплар беткән хатларын.

«Ник язмыйсың, улым, йөрәк парәм,
Шушы микән тәкъдир хөкеме?
Хат-хәбәрсез менә узып бара
Гомеремнең тагын бер көне...»

...Выжлап очты еллар, сулды йөзем,
Чигә чәчләремә чал төште;
Үкенүләр узды, дигән идем, –
Үз балам да үсеп җитеште.

Язмышкайлар кабатлана икән,
Белгән булсам шуны мин алдан...
...Күз күгәртеп хәзер хатлар көтәм
Ерактагы газиз баламнан.

**ЯЗГЫ УРАМ**

Әкрен генә кыш үткәрдем
Яндыргалап утынны.
Язгы урамны күрдем дә,
Йөрәк тагын «чукынды».
Һәр чибәрнең күз карашы
«Кил» дип чакыра мине,
Әллә барысы миңа гашыйк,
Әллә үзем шыр тиле.
Чиктән аша хыялларым,
Көчләр кайный беләктә,
Картаюга урын юк шул
Сөю тулган йөрәктә.

**АҖАГАННАР**

Яшәү мәгънәсенә төшенергә
Омтылуым туса уемда,
Өянкеләр белән пышылдашып
Йөрим төнге Уел буенда.

Кушымта:

Салмак кына дулкынланып
Шаулый иген басуы;
Сискәндереп уйландыра
Аҗаганнар балкуы.
Аҗаганнар яшьнәгәндә,
Бөрлегәннәр өлгерә;
Матур илләр бик күп җирдә,
Тик туган ил бер генә.

Болындагы пөхтә кибәннәрдән
Җиләк исе килә, бал исе;
Шундый мизгелләрдә аеруча,
Их, яшисе килә, яшисе!

Кушымта.

Туган ягым, иң кадерле җырым,
Күңелемнең изге кәгъбәсе!
Шул моңның мин нәни бер аһәңе,
Шунда димен яшәү мәгънәсе.
Кушымта.

Шушы җирнең мин бер күзәнәге,
Шуңа күрә генә булса да
Илем белән шатлык-михнәт чигеп
Яшәүләре татлы дөньяда.

Кушымта.

**КЕШЕ**

Якасыннан каптырса да
Әҗәл ташлаган ыргак,
Бер аягы гүрдә аның,
Берсе бии тыпырдап.

**ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ**

Шагыйрь җирдә яшәми ул,
Яшен булып кына яшьни.
Шагыйрь юлы кыска була,
Тик шигърият мәңге яши.

Тормыш авыр, шагыйрь – фәкыйрь.
Яшим дисәң, сыгыл, бөгел...
Шагыйрь ялланырга мәҗбүр,
Тик шигърият ялчы түгел.

**Ә ҮЗЕБЕЗ...**

Агымнарга каршы йөзә
Вөҗданлылар һәм кадыйрлар;
Без сокланып кул чабабыз:
«Баһадирлар! Баһадирлар!»
Алар өчен горурланып
Кинәнәбез, кинәнәбез,
Ә үзебез агымнарга
Иярәбез, иярәбез...

## ЯШӘП ЙӨРГӘН БУЛДЫК

Бәхет капкалары терәксез лә,
Бер ача да язмыш, бер яба.
...Ялан к...кә каеш буып, без дә
Яшәп йөргән булдык дөньяда.

Ачылмады безгә һичбер ишек,
Тик язмышны, имеш, алдадык.
Юләр саттык, комнан аркан ишеп,
Булмаганны бушка аударып.

Баш сау булса, бүрек табылыр, дип
Елап, хафаларга төшмәдек;
Яшь буыннар ансат бөгелә бит,
Терсәкләрне җиңел тешләдек.

Шома йөзләр татлы итеп әйтсә,
Тиз ышандык һәрбер юк-барга;
Байлар бал эчкәндә, су эчсәк тә,
Сер бирмәгән булдык ятларга.

Ашыбызны ашап бетердек тә
Яшебезне яшәп бетердек;
«Шома»ларны бәреп төшердек тә,
Егып, йөзләренә төкердек.

Хәзер намаз укып утырабыз,
Гомер буе динсез кылангач;
Тик барыбер һаман алама без,
Эттән ач һәм беттән ялангач.

Вакыт дигән нәрсә акча икән,
Гафилләрдән бик тиз кача икән:
Качты тормыш язы, узды җәй...
Гомер дигән нәрсә җәфа икән,
Әмма үтә икән мизгелдәй.

## ЯРЫҢ КЕРСӘ ЯТЛАР КОЧАГЫНА...

Зар түгәсең, хатыныңны әрләп,
Ни җитмәгән, диеп, тормышта?
...Ярың керсә ятлар кочагына,
Аны гаепләргә тырышма.

Дөнья куып, алтын чыңнарына
Омтылганда бөтен өметең,
Яшен түгеп салкын мендәренә,
Ни уйлады хәләл җефетең?

Портфель тотып, эшкә багышладың
Һәр төнеңне, һәрбер иртәңне;
Нигә мәхрүм иттең кочагыңнан,
Нигә ялгыз иттең иркәңне?

Дуслар белән мыжлап кинәнгәндә
Ләззәтенә хәмер парының,
Сизденме син назлы сүзгә сусап
Тилмергәнен сөйгән ярыңның?

Үзең: «Эшлим», – дигән сылтау белән
Дөнья балын шактый татыдың;

Сөю көтеп ялыкмасынмыни
Яз гөледәй чибәр хатының?

Яз чәчәге кебек гүзәл хатын
Көз җиткәнен көтеп ятармы?
Якын яры сөеп үз итмәгәч,
Үз иткәндер инде ятларны.

Гаебең зур. Кемгә үпкәлисең,
Кемне тиргәп әрни бәгырең?
Үзең сакламаган хәзинәңнең
Бүтән ярлар белгән кадерен.

**ЕЛМАЕШЫЙК**

Әйт, кадерлем, нәрсә булган?
Ач серең;
Ник моңайдың, ник коелган
Сөмсерең?
Җәйләр узды, ыржая көз,
Дисеңме?
Көзләр кебек саргаябыз,
Дисеңме?
Көз сарысы – бары шигъри
Билге ул;
Моңаерлык кайгымыни
Инде ул?
Көннәреңне юләр сатып
Туздырма,
Елап-шыңшып юкка вакыт
Уздырма.
Ни рәте бар яшь түгүнең
Аптырап?
Күрә белү тормыш күркен
Татлырак.
Табигатькә ипләп карап
Үрнәк ал:
Шаулый, чәчен җилдә тарап,
Бөдрә тал;
Узып барса да әбиләр
Чуагы,
Кызыл, яшел, сары миләш
Куагы
Әй җемелди – камаштыра
Күзләрне!
Йөрәк бозың шул яктыга
Түзәрме?
Һич булмаса, миңа кара,
Гүзәлем,
Яшәү уты белән яна
Күзләрем!
Юлда, җилдә, яңгырларда
Арсам да,
Елмаям мин бу дөньяда
Һәр таңга.
Язмышның һәр халәтенә
Түзәм мин.
Бу тормышның хәсрәте дә
Гүзәл, дим.
Әнә җилдә эзли ышык
Күбәләк.
Кил янымa, елмаешыйк

Бергәләп!

## УЙ

Ябышты бит тагын бугазыма
Бәла – сагыз;
Татлы хатирәләр юата, ди,
Ышанмагыз.

Искә алган саен яшьлегемнең
Ерак күркен,
Томалана, авырая бара
Бүгенге көн.

## ЕГЕТЛӘНҮ

Юк, картаймыйм, әле һаман туры билем,
Иләсләтә сылуларның татлы ирене.
...Автобуста бер чибәргә баккан идем,
Ул, сикереп торып, миңа урын бирде.

## ХИС

Басып бәллүрләрнең балкуларын,
Уктай ярып мәҗлес томанын,
Үзәгемне өзде күз карашың,
Халәтемнең оҗмах сыманын

Кичергәндәй булдым шул минутта,
Гүя татлы төшкә юлыктым.
Актарылды җаным, яндым утта,
Исем-җисемемне оныттым.

Ике ялгыз язмыш тәңгәл килде,
Очраклылык түгел бу һич тә.
Юкса бүтән күзләр күпме иде
Бәйрәм гөрләп торган бу кичтә.

...Бию өермәсе бөтерелә,
Юк-бар зарлар кала үткәндә;
Дөрләп яна дәртем, күкрәгемә
Күкрәкләрең тиеп киткәндә.

Күзләреңә карыйм –күз камаша,
Шул микәнни сөю шаукымы?
Җан эреткеч нәфис челтәр аша
Кулым тоя билең ялкынын.

Изрәп тоям чәчләреңнең исен...
Сизәсеңме тәннәр берлеген?
Без бер асыл хәзер, без бер җисем,
Бүленмәслек бер җан без бүген...

## СИН

Әүвәл балкып төшләремә кердең,
Синме, дидем, әллә түгелме?
Хыялымда туган пакь рәвешең
Иләс итте үсмер күңелне.

Шуннан бирле калды күз алдымда
Чакырулы уйчан күзләрең.
Шул күзләрне Идел ярларыннан,
Болак буйларыннан эзләдем;
Уйлар дәрьясында йөрдем йөзеп,
Бәхет теләп акты яшьләрем,
Табылачак хәзинәмне сизеп,
Канатланып, җырлап яшәдем.
...Калын көртләр кинәт эреп акты,
Серле утлар янды офыкта,
Март аенда шомырт чәчәк атты,
Без очрашкан изге минутта.
Шәһәремнең бөек урамнарын
Хыялымда нурга буядым:
Син күрдеңме аны, газиз ярым,
Чынга ашкан якты хыялым?
...Бүген дә шул чәчләр агарса да,
Ел артыннан еллар узышса да,
Безнең хакимебез – чибәрлек.
Мин ышанам, бәгърем, юк дөньяда
Безне аерырлык егәрлек.
Белмим инде, синме минем нурым,
Минме синең учак балкышы?
Син бит минем йөрәгемдә тудың,
Син бит минем җанның яртысы.

**КАРТЛЫК**

Картлык килде. Ул хөрмәткә лаек.
Кайсы фасылымнан ул ким инде?
«Саумы, картлыгым, – дим, – очраштык бит,
Очрашмавыбыз да мөмкин иде...»

**ЧИЛӘБЕДӘН БӨГЕЛМӘГӘ**

Тәрәзәдән карап барам.
Таулар, кырлар, тал-тирәк...
Чиләбедән Бөгелмәгә
Вагон бара келтерәп.
Поезд тизрәк чапкан саен,
Аралар якыная,
Әтием дә көлемсери,
Әнием дә елмая.
Тәгәрмәчләр җырын бүлеп
Ишетелде бер тавыш:
«Хәзер, дуслар-пассажирлар,
«Җиләк» дигән тукталыш».
Менә вокзал. Тирәсендә
Гөрләп үсә бакчалар.
Учлап җиләк өләшәләр
Юмарт әби-апалар.
Күбәләкләр очып йөри,
Болын тулы җиләклек.
Әйтсәм әйтим, учлап-учлап
Җиләк ашап кинәндек.
Киттек. Янә тәгәрмәчләр
Шакылдавы ешая.
Әтием дә көлемсери,
Әнием дә елмая.
Кинәт тагын матур тавыш:

«Үскәнем, ипләп тыңла!
Тукталышның алдагысы
«Татлы туңдырма» була».
...Нинди генә туңдырма юк:
Төрләре җитмеш җиде;
Җиде яшькә җитеп шуны
Күргәнем һич юк иде.
Җиде төрен авыз иттем,
Җитмеш төре сыймады.
(Әтием дә рөхсәт итте,
Әнием дә тыймады.)
Тагын киттек. Тагын игълан
Шатландырды күңелне.
«Уенчыклар» тукталышы
Тәрәзәдән күренде.
Бигрәк рәхәт булып чыкты
Бөгелмәгә бу барыш,
«Бәлеш» дигән станция,
«Әкиятле» тукталыш.
Саный китсәң, санап була,
Тагын әле әллә ни...
Әнием дә көлемсери,
Әтием дә әрләми.
Һәркайсына төшкән саен
Шатландым да куандым.
...Әни төртә: «Тор, улым», – ди.
Бөгелмәдә уяндым.
Күрәм: вокзал түбәсендә
Йөнтәс песи мияулый.
Әтием дә ник бер көлсен,
Әнием дә елмаймый.

* * *

Ерак язда, кереп барган чакта
Ачып тормышымның капкасын,
Офыгымда таң кояшы булып
Балкып туган иде максатым.

Атлый-атлый туздым башмакларым,
Аякларым сызлап, аксадым;
Чәчкә чаллар керде, тик каршымда
Янып торды изге максатым.

Узды тормыш. Бирмәде шул язмыш
Җылы назын, малын, акчасын.
...Офыгымда таң кояшы булып
Һаман әле яна максатым.

## ФАРАЗ

Үзең дә бит миңа тартыласың!
...Мин дә кыймыйм, син дә базмыйсың.
Күкрәгемә кысып башкаеңны,
Чәчең сыйпап килә назлыйсым,
Куенымда килә иркәлисем,
Бергә көтеп таңнар туасын,
Иләсләнгән кайнар учым белән
Йөрәк тибүеңне тоясым.
Иңнәремә изрәп сарыласың.
(Фаразларым шундый сизгер лә!)

Сулышымны көтә иреннәрең,
Йөзләр якынлашкан мизгелдә.
Онытыла дөнья, күзләреңнең
Ләззәтеннән күзләр камаша...
Шул минутта кинәт айнып китәм,
Син минеке түгел ләбаса!

**КАЙТТЫМ**

Кайда, кайда, кайда минем
Каеннарым, талларым?
Егерме ел читтә йөреп
Кайттым – таный алмадым.
Карлыгачлар оя корыр,
Ерткыч җәнлек өн казыр.
Торган җирдә каберем калыр,
Туган илдә ни калыр?
Авыл юлын буйлап үсә
Арыш, бодай, борчаклар.
Бер утырып елыйм әле,
Арышларын кочаклап.

**КҮРШЕМ**

Күршем сәер, таныш-белешләргә
Минем хакта: «Ул бик хәтәр», – ди.
Хуш сүз әйтсәм, кукыраеп йөри,
Тәнкыйтьләсәм: «Ул бит татар», – ди.
Күзгә карап: «Дуслык, туганлык», – ди,
Күрмәгәндә: «Үрчи татар», – ди.
«Татар булган җирдә дөнья тар», – ди,
«Татар исән чакта җир тар», – ди.
Һәлакәткә дучар булып калсам,
Читкә карап: «Батса батар», – ди.
Морадыма җитеп үсеп китсәм,
«Җирне баса мәлгунь татар», – ди.
Ә мин исә, кырын карашларга
Исем китеп, кырын яталмыйм.
Тормыш сөеп, дөбердәтеп яшим.
Дөрләп яшим, чөнки татар мин!

**ВАКЫТ ЮК**

Мәшәкатьле заман. Бер сүзеңне
Ишетәсе иде, ичмаса.
Көн сүрелгәч кенә шатлык калка,
Төннәр җиткәч, төннәр очраша.

Юк-бар ыгы-зыгы... Арабызда
Наз-серләребезне кем ташыр?
Җаннарыбыз, күңел күзләребез,
Рухларыбыз кайчан очрашыр?

**ТАБИГАТЬ**

Бу дөньяның фани казанына
Бар нәрсәне парлап салганнар.
Һәр ялганда хак сүз тамчысы бар,
Һәр чынлыкта әзрәк ялган бар.

Һәрнәрсәне чама белән бирә,
Табигать ул – кырыс диктатор.
Даның артып, чиксез үсеп китсәң,
Мәтәләчәгеңне көт тә тор...

*** * ***

Язлар килсә, дуслар, кайтмам әле
Хатирәләр булып мин сезгә.
Гөлләр ае болай да бит матур,
Язлар көләч булыр минсез дә.
Көзен исә мине сөйгән җаннар
Искә алсын мәҗнүн җырчысын;
Көз сагышын җиңеп, сез дусларны
Мин чыгарган моңлы җыр җыйсын.
...Сагышларда килә юатасым,
Шатлыкларда килми борчыйсым.

## БИРМИМ

«Бик пөхтәләп...» – дигән була,
Пөхтәлеге кайда ул!
...Әҗәткә дип биргән китап
Бик таушалып кайта ул.

Китапларны өйдә саклау
Яхшырак дип саныйм мин;
Сорама да, сорамыйм да,
Бирмим дә һәм алмыйм мин.

Зарурлыгын куям аның
Хатын белән бер рәткә.
Хатынны да, китапны да
Бирмим, бирмим әҗәткә.

## СЕЗ ҺӘМ МИН

Елау дигән гадәт үтте инде,
Кипте инде корып яшьләрем;
Мин дөньяның бәхетен көтеп түгел,
Хәсрәтенә чыдап яшәдем.

Ә сез, бәхет көтеп яшәгәннәр,
Булмаганны көтеп ардыгыз;
Түземсезлек утларында көеп,
Саргаешып китеп бардыгыз.

Сезне җирдән элек сабырсызлык,
Соңра өметсезлек биздерде;
Ә мин исә яшим бәхет итеп
Йөрәк сызламаган мизгелне.

## ҖӘЙГЕ ЮЛДА

Ике көпчәк чаба җәйге юлдан,
Чикерткәләр булып, әй, сикер!
Артта калып сүнә шомлы уйлар,
Ләззәт биреп туа һәр фикер.
Юкка чыга бөтен сагыш-хәсрәт,

Борчылулар фани юк-барга;
Барган кебек булам сәпитемдә
Авылыма, сабый елларга.
«Велосипед» – әй килбәтсез исем,
«Сәпит» җанга бигрәк ятымлы;
«Сәпитем» дип майлап-җайлап торам
Пар көпчәкле җитез атымны.
(Мәктәпләрдә, өлкәннәрне тыңлап,
«Ве-ло-си-пед» диеп этләндек;
«Сәпит» дисәң, зурлар көлә иде:
«Менә мәмдәлләшеп беткәнлек!»
Әй, агайлар, аңламадыгызмы
Тел ачкычын, холык чишмәсен?
Мәмдәл авылында туган малай
Мәмдәлләшми инде нишләсен?)
...Пар тәгәрмәч чаба җәйге юлдан,
Саесканны узып оч кына!
...Урал артындагы далалардан
Мәмдәлемә күңел ашкына...

**КАЛГАН БУЛСАМ...**

...Бергә булыр идек, калган булсам
Сине тыңлап шулчак әгәр дә...
Мин калмадым туган авылымда,
Син китмәдең шаулы шәһәргә.

Сулып беттем, сине уйлый-уйлый,
Саный-саный соры ташларны.
Язмыш микән безне харап итә,
Үзебезнең юләр башлармы?

Хәтеремдә калган рәвешеңне,
Тормышымның таңын сагынам.
Ә син исә бүтән инде хәзер,
Очрашсак та, мине танымассың.
...Хәер, мин дә сине танымам.

**ДИВАНА**

Төшләремдә уттай тәннәреңнең
Һәр карышын үбеп шатланам.
Тойгыларым шашып, ярсып, үксеп,
Кайнар күкрәгеңә капланам.

Син чагылып киткән аргы якка
Йөзгән кебек булам су ярып.
Иреннәрең тәмен иренемдә
Сизгән кебек булам уяныб.

Әй дивана! Яшәмәкче булам
Бутап кичә белән бүгенне.
Яратылып һәм яратып йөрер
Заманнарым узган түгелме?

**ЭЧТӘЛЕК**

Вакыт ................................
Вагон тәрәзәсеннән .......................
Мин ................................
Ижат ................................
Тарих ................................

Кәккүк ...............................
Бәләбәй ...............................
Хыянәт ...............................
Яшик… ...............................
Акыл .................................
Нишләмәк кирәк?.. ........................
Еллар үткән ............................
Мәгънә ...............................
Үкенмим ..............................
Татар бәйрәме ...........................
Экспромт ..............................
Татарлыгым ............................
Ике ватан ..............................
Соң булыр .............................
Җавап ................................
Кулъязмалар ............................
Бирәү генә гомер .........................
Хатирәләр .............................
Чабыш ................................
Бәндә ................................
Мәскәү. Кызыл мәйдан .....................
Ике тормыш ............................
Акчарлак ..............................
Без .................................
Бүген шат мин ...........................
Кайтырбыз .............................
Гармония ..............................
Тагын... ...............................
Alma mater .............................
«Алтын гасыр» ..........................
Улыма ................................
Дошманыма рәхмәт әйтәм ...................
Хисләр ...............................
Юл экспромты ..........................
Хатыннар ..............................
Троицк каласы ...........................
Аңлашу ...............................
Тозсыз шигырь ..........................
Бердәмлек .............................
Традиция ..............................
Тарихны кем яза? .........................
Татар мөгаллимәсе ........................
Бүгенге халәтем ..........................
Татар ................................
Адәм баласы ............................
Татарча ...............................
Кырыс түрәгә ...........................
Түрәләр өчен борчылу ......................
Иреннәрең .............................
Үлеп кара ..............................
Сукранам ..............................
Акыл сатам .............................
Саниягә ...............................
Кызлар ...............................
Эзлим... ...............................
Дөнья ................................
«Татар җыры» фестивале ....................
Шигъриятнең иң зуры ......................
Мәмдәл – Истамбул .......................
Тарих ................................
Юлда ................................
Язасы иде... ............................
Миңа җиткән... ..........................

Тормыш – бирәү ..........................
Бәһа .................................
Мәхәббәттән соңгы мәхәббәт .................
Кичер ................................
Табигать ..............................
Синсез ................................
Син еракта чакта ..........................
Сөю .................................
Шигырь язам ...........................
Күз .................................
Гомер ................................
Киттең ...............................
Кинәт ................................
Максат ...............................
Киләм ................................
Бурычлар ..............................
Гаиләбез ..............................
Алар һәм без ............................
Яз ае .................................
Кемгә хат языйм? .........................
Байлык һәм бәхет .........................
Өебездә ...............................
Кем гаепле? ............................
Күзге этюд .............................
Ике аваз ...............................
Шагыйрьләр һәм түрәләр ....................
Тормыш яме ............................
Яз һәм күз .............................
«Монда шыткан милли эшләр...» ...............
«Әй җырлыйсың тыпырдап та...» ..............
Мәдхия ...............................
Әтием кабере янында ......................
Җәлил сурәте ...........................
Үсеп җиттең, улым ........................
Мәтрүшкәле чәй ..........................
Туфан ................................
Бик еракта .............................
Казанда кунакта ..........................
Ике җәза ..............................
Үзгәрмәгән .............................
Гөләп ................................
Күз башы ..............................
Үпкәләшкәч ............................
Яз ...................................
Көнләшүем – сөюдән .....................
Кайда булды уйларың? .....................
Озату ................................
Күз .................................
Хыяллар ..............................
Минем исә... ............................
Яшим ................................
Аерылышу .............................
Җәйдә яшьнәп... .........................
Кайда мәгънә? ...........................
Белеп торган идек .........................
Кичердеңме икән? ........................
Соңарган мәхәббәт ........................
Сарыкүл ..............................
Хатлар көтәм ...........................
Язгы урам .............................
Аҗаганнар .............................
Кеше ................................
Шагыйрь һәм шигърият .....................

Ә үзебез... ..............................
Яшәп йөргән булдык ........................
Ярың керсә ятлар кочагына... ..................
Елмаешыйк ..............................
Уй ...................................
Егетләнү ................................
Хис ...................................
Син ...................................
Картлык ................................
Чиләбедән Бөгелмәгә .........................
«Ерак язда, кереп барган чакта...» ................
Фараз .................................
Кайттым ................................
Күршем .................................
Вакыт юк ................................
Табигать ................................
«Язлар килсә, дуслар, кайтмам әле...» .............
Бирмим .................................
Сез һәм мин ..............................
Җәйге юлда ..............................
Калган булсам... ...........................
Дивана .................................
Литературно-художественное издание

**Сабиров** Ирек Нагимович

**НАСЛАЖДЕНИЕ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Сабиров** Ирек Нәгыйм улы

**ЛӘЗЗӘТ ТАШКЫНЫ**

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова.* Рәссамы *Д.А.Шульятьева.* Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина.* Корректоры *Г.Г.Гарифуллина.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2010. Форматы 70×90 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 4,09. Тиражы 1000 д. Заказ О-1902. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http:// tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.